وَٱعْتَصِمُوا۟ بِحَبْلِ ٱللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا۟

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№1 (234). ГЫЙНВАР – 2015 / РАБИГЫЛӘҮВӘЛ-РАБИГЫЛАХЫР – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

**Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**



*Халкыбыз – догалы халык*

**Кол Шәриф мәчетендә тәүлек дәвамында берөзлексез Коръән укый башладылар**

8 бит

## Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

# «АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ МӘРХӘМӘТЕНӘ ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ ҺӘМ ДОГАЛАРЫБЫЗДА БӨТЕН ДӨНЬЯДА ТЫНЫЧЛЫК САКЛАНУЫН СОРЫЙБЫЗ»

**Без бик үк гади булмаган заманда яшибез. Глобальләшү процессы бөтен дөнья халыкларын бер-берсенә бик якынайта. Шул ук вакытта, кызганыч, әлегә кадәр кеше хокуклары нигезен тәшкил иткән яшәү хокукы һәм сүз иреге хокуклары бозылу очракларына тарыйбыз. Шунысы да мөһим икәнне онытмасак иде - сүз ирегe һәр мәдәнияткә, милләткә, дингә карата хөрмәт һәм сабырлык күрсәтүгә таянырга тиеш. Башкаларны мыскыл итәргә, түбәнсетергә ярамый, югыйсә бу демократия кыйммәтләреннән һәм гражданлык җәмгыятеннән турыдан-туры читләшүгә китерә.**

Әлегә кадәр дөньяның кайбер нокталарында икеле стандартлар күзәтелә. Әйтик, афроамериканнарны түбәнсетү - расизм, яһүдиләрне түбәнсетү - антисемитизм; ә кайберәүләр, 1,7 миллиард мөселманны түбәнсетеп, моны "сүз ирегe" дип атый.

Франциядә килеп чыккан хәлләр барчабызда борчу тудырды. Бу хәлләр бөтен кешелеккә, иң беренче чиратта, исламга кизәнү, дип саныйм. Бөтен дөньяга мөселманнарны террорга һәм көч куллануга булышучылар итеп күрсәтү сизелә. Без берничек тә террордан һәм көч кулланудан торган гамәлләрне яклый алмыйбыз - бу адымга бер генә дин дә, шул исәптән, ислам да бармаячак.

Билгеле, тынычлык даими саклана торган күренеш түгел, һәр яңа буын аның өчен көрәшә һәм үзара файдалы мөнәсәбәтләр корырга омтыла. Кешелек үз адымнарын хәзерге вакыт һәм үткән буыннарның тәҗрибәсен исәпкә алып ясаганда гына нәтиҗәләргә ирешә ала. Югыйсә һәр яшь буын үзенә кадәргеләрнең тәҗрибәсеннән баш тартса - шул бер үк тырмага баскан кебек булыр. XX гасыр бит ике дөньякүләм сугыш белән тарихка керде. Кайбер экспертлар, XXI гасырда исә илләр арасында түгел, ә цивилизацияләр арасында конфликтлар килеп чыгар, диләр. Бездән, барлык диннәр һәм милләтләр вәкилләреннән, толерантлык идеясенә таяну, бер-беребезгә карата сабыр, түзем булу, үзара хөрмәт күрсәтүдә тагын да ныграк берләшү сорала. Мин цивилизацияләр арасында конфликт китереп чыгарырга һәм шуның белән төрле илләрдә яшәүчеләр йөрәгендә курку хисе тудырырга теләүчеләрнең максатларына ирешмәячәгенә ышанам.

***(Ахыры 3 нче биттә.)***



3 бит

*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия дин әһелләрен Болгарга Мәүлид бәйрәменә җыйды*

## ТЕЛӘКТӘШЛЕК БЕЛДЕРӘБЕЗ

***ТР МДН Грозный шәһәрендә Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә кагылышлы карикатураларга каршы үткәрелүче митингка теләктәшлек белдерә***

Европа берлегенең төрле басмалары тарафыннан карикатуралар бастырылуы Татарстан мөселманнарында борчу тудыра.

Сүз иреге кешенең, нинди генә конфессия вәкиле булса да, рухи кыйммәтләрен һәм әхлакый идеалларын мыскыл итәргә тиеш түгел. Югыйсә җимергеч социаль киеренкелек туарга мөмкин. Чөнки бу халыкларның бүгенге җәмгыятьтә тынычлыкны саклап, үзара килешеп яшәргә омтылышларына каршы килә.



Теләсә кайсы радикаль һәм экстремистик күренеш дини карашлар белән акланырга тырышкан кебек үк, сүз иреге социаль җавапсызлыкка нигезләнә алмый.

Кешенең вөҗдан иреге, рухи кыйммәтләре - берәүгә дә бозарга рөхсәт ителмәгән төп хокуклар чагылышы.

## АЛАБУГА РАЙОНЫ ИМАМ-МӨХТӘСИБЕ ВАФАТ БУЛДЫ



Алабуга районы имам-мөхтәсибе Әзмәл хәзрәт Саматов вафат булды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Әзмәл хәзрәтнең якыннарының тирән кайгысын уртаклаша һәм Аллаһы Тәгаләдән мәрхүмнең гаиләсенә бу кайгыны күтәрергә көч бирүен сорый.

Әзмәл хәзрәт озак еллар Алабуга районы имам-мөхтәсибе булып торды һәм үз вазыйфасында күп уңышларга иреште. Аның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә районда ислам дине үсеше күзәтелде, мәчетләр ачылды, яшь буын үзенең дине белән тагы да якынрак танышу мөмкинлегенә ия булды.

Әзмәл хәзрәтнең урыны фирдәвес җәннәтләрендә булса иде.

## МӘЧЕТЛӘР ТӨЗҮ ДӘВАМ ИТӘ

***Узган ел татарстанда 20 мәчет ачылды, 10 мәчет төзелеше тәмамланып килә. Моннан тыш дини йолаларны башкару өчен 2 җеназаханә комплексы эшли башлады. Мәчетләр каршында 3 мәдрәсә төзелде. Дини корылмалар төзү эшләре быел да дәвам итә.***

Күптән түгел Зәйдә яңа мәчет ачылды. Ачылу тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, район башлыгы урынбасары Марсель Хуҗин, район мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт Камалов, күрше район имам-мөхтәсибләре, мәхәллә халкы һәм чакырылган кунаклар катнашты. Мөфти халыкны әлеге истәлекле вакыйга белән тәбрикләп, үзенең үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде. "Мәчетнең Мәүлид аенда ачылуы игътибарга лаек. Исламда мәчет гыйбадәт кылу өчен генә түгел, ә иҗтимагый чаралар уздыру урыны буларак та кулланыла. Мәчет мөселманнарның яшәү үзәге дә", - дип билгеләде мөфти.

Мәчетнең имамы итеп Рөстәм хәзрәт Дәминов билгеләнде. Яңа җитәкчегә Камил хәзрәт чапан бүләк итте, ә мәчетнең төзелешендә актив катнашкан иганәчеләргә Рәхмәт хатлары тапшырды. Район башлыгы урынбасары Марсель Хуҗин сүзләренчә, яңа Тынычлык мәчете районда 29 нчысы, ә район үзәгендә 5 нчесе.

Мәчетне ачу тантанасы Мәүлид бәйрәме чарасы һәм зур мәҗлес белән тәмамланды.

***

***Балтач районының Чапшар авылында яңа мәчет ачылды. Чарада Татарстан мөфтие урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Илдар хәзрәт Баязитов һәм Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел" исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, ТР Конституцион суды рәисе Фәрхәт Хөснетдинов, Балтач районы башлыгы Рамил Нотфуллин, эшмәкәр Фәрит Мифтахов, район имамнары һәм җирле халык катнашты.***

Татарстанның баш казые һәм Балтач районы мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев әйтүенчә, Чапшар авылындагы яңа мәчет районда 41нчесе; 30 дан артык хуҗалыгы булган барлык авылларда да мәчет эшләп килә. Бүгенге көндә Чапшар авылында 340 кеше яши һәм 80 хуҗалык бар.

Мәчет авыл халкы ярдәме һәм ТР Дәүләт Советы депутаты Камил Гайнетдинов һәм Төмән эшмәкәре Муллагомәр Шиһапов булышлыгы белән төзелде. Алар икесе дә тумышлары белән Чапшар авылыннан.

Яңа мәчетнең имамы итеп Мулланур хәзрәт Әсәдуллин билгеләнде. Ул озак еллар Чапшар авылы мәктәбендә укыта, дини белемне "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел" исемендәге мәдрәсәдә ала. Мулланур хәзрәт авылда төрле дини чараларда катнаша, балаларга дини белем бирү белән шөгыльләнә.

## ТАТАР ДИНИ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН ТОРГЫЗУ ҺӘМ МӨСЕЛМАН ӨММӘТЕН БЕРЛӘШТЕРҮ ДӘВАМ ИТӘ

***Гыйнварның 14 ендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашып, аңа нәзарәтнең үткән елдагы эшчәнлеге турында сөйләде һәм бу елга уй-ниятләре белән уртаклашты. Әлеге рәсми очрашуда ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров һәм мөфти урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин дә катнашты.***

Мөфти нәзарәтнең үткән елдагы эшләре турында сөйләгәндә: "Мәгълүм булганча, 2014 елны дини традицияләрне торгызу елы буларак уздырдык. Югалган, онытылган йолаларыбызны кире кайтару ниятеннән ел башында Болгарда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә багышланган дини бәйрәм үткәрелде. Быел да шундый ук тантаналы чаралар үтте. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән 300 дән артык кунак җыелды. Ай календаре буенча киләсе Мәүлид бәйрәме бу елның 22 декабренә туры килә. Бу уңайдан ел ахырында тагын да масштаблырак чаралар үткәрү планлаштырыла", - диде.



Сөйләшү барышында Кол Шәрифтә Коръән хәтем чыгу турында да сүз булды. "Изге Китапны 36 коръәнхафиз 30 сәгать эчендә укып чыга. Аннары Аллаһы Тәгаләдән Татарстан һәм халкыбыз өчен бәрәкәт, иминлек сорап дога кылалар", - дип аңлатма бирде мөфти хәзрәт.

2014 елда революциягә кадәр таралган татар рухи мирасына зур игътибар бирелде. Махсус сайтка татар дин әһелләренең архивлардан табылган китапларының электрон вариантлары урнаштырылды. "Хузур" нәшрият йорты 50 китап бастырды. 10 аудио китап чыгарды. Бастырыр өчен 30 дәреслек һәм 42 фәнни-популяр китап әзерләнде. Китаплар бастырудан тыш нәшрият йорты быел Болгар җыенында беренче Россиякүләм дини китаплар ярминкәсен уздырды.

Шулай ук барлык дини гыйбадәтләрне һәм йолаларны безнең төбәккә хас хәнәфи мәзһәбе (хокукый мәктәбе) өйрәтүләре буенча уздыруның бердәм стандартлары әзерләнде. Алар "Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында нигезләмә" китабына тупланды, бастырылды, имамнарга таратылды.

Моннан тыш нәзарәт Россиядә беренче тапкыр мәдрәсәләр өчен уку-укыту стандартларын эшләде. Тиздән аның презентациясе үткәреләчәк. Идел буе имамнарының гыйлемен күтәрү курсларын камилләштерү буенча актив эшләр алып барыла, аларда 400 дән артык имам белем алды.

Нәзарәт Теләче районының Иске Җөри авылында инвалид ятим балалар приютын ачты. Алга таба наркоманнарны һәм эчкечеләрне тернәкләндерү үзәге ачу, төрмәләрдән чыгучыларга ярдәм итүне оештыру планлаштырыла.

Камил хәзрәт узган ел мөфтият тарафыннан уздырылган кайбер күләмле чараларны да искә төшерде. "Казан-Арена" стадионында Республика ифтары үткәрелде, анда 3 меңнән артык кеше катнашты. 2015 елда 7 мең кешегә ифтар оештыру планлаштырыла. Моннан тыш Корбан бәйрәмендә "Яңа гасыр" каналы белән берлектә инвалид ятим балалар приюты өчен хәйрия җыю максатыннан "Сөючеләр фида кыла" телемарафоны уздырылды.

Мөфти сүзен: "Быел да татар дини традицияләрен торгызу һәм саклау буенча эшләр дәвам итә. Нәзарәт пленумында бу елны "Татар дин галимнәре" елы дип игълан итү турында карар кабул ителде. Шуның белән бәйле рәвештә республиканың барлык районнарында дин галимнәре тормышы, эшләре хакында материаллар җыю оештырыла. Ел ахырында инкыйлабка кадәр һәм совет чорында динебезгә, халкыбызга хезмәт иткән татар дин галимнәре турында альманах чыгару күз алдында тотыла", - дип тәмамлады.

Президент белән очрашканнан соң нәзарәт вәкилләре журналистлар сорауларына җавап бирделәр. Әлеге сөйләшү барышында мөфти урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин: "Президент республикабыз мөселманнары белән корылган эш формасының Татарстан өчен яраклы һәм уңай булуын ассызыклап үтте. Мөселманнар күп, төрле. Алар мәчетләргә генә йөрми, җәмгыять тормышында да катнаша. Президент, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте аларның һәркайсы белән дә эшли белергә тиеш, дигән фикерен җиткерде", - диде.

Камил хәзрәт, каләм ияләре сорауларына җавап биреп: "Без алга таба да динебезгә, республикабызга бергәләп хезмәт итәрбез, мөселманнар өммәтен берләштерүне дәвам итәрбез", - диде.

## ТАТАРСТАНДА ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ ЭШЛӘНДЕ

***Татарстанда "Урта һөнәри дини белем бирү стандартлары" эшләнде. Аны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Россия ислам институты, мәдрәсәләр, ТР Фәннәр академиясе, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белгечләре ике ел дәвамында әзерләде.***

Бердәм стандартларны әзерләү һәм гамәлгә кертү буенча эшче төркем 2013 елның апрелендә оештырылды. Мөселман мәгарифе башлангыч, база һәм югары белем бирү дәрәҗәләренә бүленеп, алга таба өч дәрәҗәгә туры килгән белем бирү стандартлары проектларын әзерләү эше башланды. Хәзерге вакытта өч юнәлештә стандартлар расланды:

"Ислам фәннәре һәм тәрбия", башлангыч әзерлек;

"Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле", төп әзерлек;

"Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле", югары әзерлек.

Әлеге стандартлар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы экспертизасын уңышлы үтте. Татарстан мөфтие, ТР МДН рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин "Урта һөнәри дини белем бирү стандартларын раслау һәм гамәлгә кертү турында"гы боерыгы (№74, 12.11.2014) белән әлеге стандартларны раслады.

Боерык нигезендә, 2015-2016 нчы уку елыннан башлап, ТР МДНнә караган мәдрәсәләрдә шәкертләргә белем әлеге стандартлар нигезендә биреләчәк.

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ МӘРХӘМӘТЕНӘ ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ ҺӘМ ДОГАЛАРЫБЫЗДА БӨТЕН ДӨНЬЯДА ТЫНЫЧЛЫК САКЛАНУЫН СОРЫЙБЫЗ

*(Башы 1 нче биттә.)*

Франциядә килеп чыккан явызлык - барчабыз өчен дә тынычлыкны саклауның никадәр мөһим икәнен аңлатучы сабак булды. Әлбәттә, үзенчәлекле фикер йөртә алу - җитлеккән шәхесләргә хас сыйфат. Әмма, шул ук вакытта, җәмгыятьтә экстремизмга җирлек була алырдай аңлашылмаучанлык тудыручы фикерләргә, гамәлләргә юл куелырга тиеш түгел.

Нәкъ менә ислам бар дөньяга тигезлек, гаделлек һәм дин иреге төшенчәләрен аңлатты. "Гарәпнең гарәп булмаган кешедән өстенлеге юк", - дип өйрәтте Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи үә сәлләм. Изге Коръәндә ("Әнгам (Терлек)" сүрәсе, 108 нче аять) мөселманнарга башка дин әһелләрен түбәнсетү тыелганлыгы турында ап-ачык әйтелә. "Мөшрикләрнең Аллаһка тиң күреп табына торган сыннарын сүкмәгез", - диелә Изге Китапта. "Бәкара"" сүрәсенең 256 нчы аятендә әйтелә: "Дингә көчләү юк". Заманында, яһүдләр Европада эзәрлекләүләр барган чорда Кордов хәлифәтендә сыену урыны тапканнар. Кайчак безгә үрнәк алыр өчен тарихыбызның искә төшерү дә кирәк!

Кешелек мәдәнияте мозаиканы хәтерләтә. Без - күптөрле. Әмма бу безнең арада бәхәсләр булырга тиеш дигән сүз түгел. Киресенчә, безне берләштергән үзенчәлекләргә игътибар итик. Мәсәлән, Татарстан Республикасында нәкъ шуңа омтылалар да. Республикада берничә йөз еллар дәвамында мөселманнар һәм православлар тату-тыныч яшиләр. Православлар да, мөселманнар да үзләренең үзенчәлекләрен саклыйлар, шул ук вакытта берберләрен хөрмәт итәләр. Бары тик Казанда гына мәчеттән чыккач, чиркәүне күрергә мөмкин, ә Иске татар бистәсендә яһүдләр мәктәбе урнашкан, староверлар чиркәве католиклар гайбадәтханәсе белән беррәттән тора. Дөньяның башка бер генә урынында да мондый күренеш юктыр! "Татарстан моделе" термины фәнни әйләнешкә ныклап керде һәм ул бар кешелек өчен үрнәк. Халык милли-дини үзенчәлекләрен саклап та тыныч, имин, мул тормышта яши ала.

Франциядә килеп чыккан кызганыч хәлләр шактый проблемалар барлыгын күрсәтте. Әлеге проблемаларны бер ил ялгызы гына хәл итә алмый. Алар бер мизгелдә барлыкка килмәде, шактый вакыт дәвамында җыела барды. Кызганыч, аларны хәл итү белән берәү дә шөгыльләнмәде. Бу хәлләр бер төбәк вакыйгасы гына түгел, ә иң югары дәрәҗәләрдә, үзара аңлашып, хәл ителә торган дөньякүләм вакыйга.

Дөньякүләм җәмгыять Россия Федерациясе тәҗрибәсен исәпкә алырга тиеш. Россиядә 200дән артык милләт вәкилләре, төрле диннәрне тотучылар тыныч яши. Һәр социаль төркем дәүләтне ныгытуга үз өлешен кертә.

Сүземне йомгаклап, барлык мөселманнарны сабыр, түзем булырга һәм төрле котыртуларга бирешмәскә чакырам. Без, мөселманнар, Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәтенә өмметләнәбез һәм һәр көн догаларыбыз белән бөтен дөньяда тынычлык, иминлек саклануын сорыйбыз.

*Татарстан мөфтие*
*Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

# Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Россия дин әһелләрен Болгарга Мәүлид бәйрәменә җыйды

***Гыйнвар ае вакыйгаларга бик бай булды. Шуларның берсе - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Болгарда оештырылган Мәүлид бәйрәме "Ак мәчет"кә Россиянең төрле төбәкләреннән дин әһелләрен, мәртәбәле кунакларны җыйды.***



Бәйрәм чарасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Мәскәү һәм Чувашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов һәм башкалар катнашты. Төмән, Самара, Ульяновск, Пенза, Волгоград, Пермь, Түбән Новгород, Дагыстан - барлыгы 20 гә якын төбәктән мөфтиләр килгән иде.

Иң әүвәл барлык дин әһелләре бергәләп мәчеттә өйлә намазын укыды. Намаздан соң Мәүлид бәйрәме уңаеннан котлаулар яңгырады.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәүлид ән-Нәбинең татар халкы уздыра торган иң борынгы бәйрәмнәрнең берсе булуын билгеләп узды. "Мәүлид көнендә без Аллаһ Рәсүленең дөньяга килүенә шатлык белдерәбез. Аллаһы тәгалә Коръәннең "Юныс" сүрәсендә әйткән: "Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам! Кешеләр Аллаһның юмартлыгы вә рәхмәтенә шатлансыннар!" Аллаһы тәгалә безгә Үзенең рәхмәтләре өчен шатланырга кушкан, ә Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) - Раббыбызның рәхмәтләренең иң зурысы. Чөнки Раббыбыз Коръәндә шулай дигән: "Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек". Шулай булгач, без бу көндә шатлыгыбызны белдерик, Аллаһы тәгаләдән догалар кылыйк, әҗер-саваплар сорап, шөкерләр әйтик", - диде Татарстан мөфтие.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Болгар тарихи-археология комплексының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүен искә төшерде. "Болгар җиренең исламны кабул итү урыны булуы исемлеккә кертү карарын кабул иткәндә зур роль уйнады", - диде ул.

Бәйрәмдә мөнәҗәтләр, салаватлар әйтелде, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмгә багышланган касыйдә укылды. Чараны "Ак мәчет" имам-хатыйбы Руслан хәзрәт Фәрхетдинов алып барды.

***

Бәйрәм чаралары башланыр алдыннан Болгарда ТР МДНнең 2015 елдагы беренче Президиум һәм Пленар утырышлары үткәрелде. Анда Татарстан имамнары 2015 елны Диния нәзарәте тарафыннан "Татар дин галимнәре елы" буларак үткәрергә дигән карар кабул иттеләр.

# "ШУРА" АЛЬМАНАХЫН БӨТЕН РОССИЯГӘ ТАРАТУ МӘСЬӘЛӘСЕ КАРАЛА

Мәгълүм булганча, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты, революциягә кадәр зур абруй казанган "Шура" журналын торгызып, аны кварталга бер тапкыр нәшер итә башлады. Альманахта республика мәчетләрендә сөйләнергә тиешле җомга вәгазьләре урын алып килә. Республиканың барлык мәчетләрдә бер төсле җомга вәгазьләрен уку тәҗрибәсе Россиянең башка төбәкләрендәге нәзарәтләрдә дә зур кызыксыну уяткан. Хәзерге вакытта Бөтендөнья татар конгрессының координацон советы аша альманахны Россиянең барча татар имамнарына тарату мәсьәләсе карала.

**"Шура"ның 7 нче санында хәбәр ителгәнчә, Татарстан мәчетләрендә түбәндәге темаларга җомга вәгазьләре сөйләнәчәк:**

**30 нчы гыйнвар** (рабигылахыр аеның 9 нчы көне) вәгазе - "Ришвәттән ерак булыйк";
**6 нчы февраль** (рабигылахыр аеның 16 нчы көне) вәгазе - "Гөнаһлары өчен оялучының тәүбәсен Аллаһы кабул итәчәк";
**13 нче февраль** (рабигылахыр аеның 23 нче көне) вәгазе - "Ислам динендә канәгатьлек";
**20 нче февраль** (җөмәдиәләүвәл аеның 1 нче көне) вәгазе - "Вәгъдәдә тору - имамнан";
**27 нче февраль** (җөмәдиәләүвәл аеның 8 нче көне) вәгазе - "Иблиснең мәкерле юллары";
**6 нчы март** (җөмәдиәләүвәл аеның 15 нче көне) вәгазе - "Гомер буе хөрмәтлик!";
**13 нче март** (җөмәдиәләүвәл аеның 22 нче көне) вәгазе - "Зина - зур гөнаһ";
**20 нче март** (җөмәдиәләүвәл аеның 29 нчы көне) вәгазе - "Коръәннең ачкычы";
**27 нче март** (җөмәдиәлахыр аеның 7 нче көне) - "Үлем турында".

# Балтачта борынгы мәдрәсә даны бүгенге көннәргә кайтты

***Балтач районы Кариле авылындагы мәдрәсәгә 300 ел тулды. Татар дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани мәгълүматлары буенча, Казан артының төрле авылларында имамлык иткән күп сандагы татар дин әһелләре шушы мәдрәсәдә Габдессәлам хәзрәттән дәрес алганнар.***

Ризаэддин Фәхреддиннең "Асар" хезмәтендә дә Кариле мәдрәсәсенә һәм анда дини гыйлем биргән мөгаллимнәргә, укыган муллаларга кагылышлы күп сандагы мәгълүматлар тупланган.

Бүгенге көндә авылда мәчет эшләп тора, яңа иман йорты 20 ел элек салынган.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Кариле авылы халкын бәйрәмнәре белән котлады һәм 80 яшьлек имам-хатыйб Әгъзам хәзрәткә, динебезгә, халкыбызга хезмәте өчен рәхмәт әйтеп, ТР МДНнең медален тапшырды.

Авыл бәйрәменә шулай ук мөфти урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Рәфыйк Мөхәммәтшин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин һәм башка имамнар кайткан иде.

# ТӘҮБӘ ИТҮ ТУРЫНДА

**"Ий, мөэминнәр, һәммәгез дә Аллаһыга тәүбә итегез, шаять, дөнья вә ахирәттә бәхетле булырсыз". *("Нур" сүрәсе, 31 нче аять).***

Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы тәгалә исеме белән... Бу дөньяны бар иткән, чиксез нигъмәтләр биргән Аллаһы тәгаләгә мактауларыбыз! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә сәламнәребез барып ирешсә иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем!

Кешелекне караңгылыктан чыгарган, дөрес юл күрсәткән, җәберләнүчеләргә булышкан, кешелекнең чын коткаручысы булган Аллаһы тәгаләнең яраткан пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә сәламнәребез барып ирешсә иде. Аңа, аның гаиләгъзаларына, сахабәләренә, бүгенге көнгә кадәр аның юлыннан баручыларга сәламнәребез барып ирешсә иде.

Яшерен яки ачык кимчелекләре булган кешенең Аллаһы тәгаләгә тиешенчә гыйбадәт кыла алмавы барыбызга да билгеле. Бары тик фәрештәләр генә гөнаһлардан ерак тора һәм Аллаһы тәгаләнең әмерләрен төгәл үти. Кешеләрнең гөнаһларга бирелүләренең сәбәбе аның һәрвакыт нәфес һәм шайтан белән көрәштә булуында.

Кадерле мөселманнар!

Нәфес кешегә һәрвакыт начар нәрсәне генә боерып тора. Бу мәсьәләдә Йосыф галәйһиссәлам дә аңа яла итеп якканны эшләмәвен аңлатканда болай ди: **"Әммә шулай да булса нәфесемне дөресләмим, чөнки нәфес явызлыкка өндидер, мәгәр нәфес өндәгән явыз эшләрдән котылыр Раббым рәхмәт кылган кешеләр генә. Әлбәттә, минем Раббым ярлыкаучы вә рәхмәтле" *("Йосыф" сүрәсе, 53 нче аять).*** Бу сүзләре белән ул кеше табигатенә начарлыкка бирелү сыйфаты хас икәнен әйтергә тели. Аллаһы тәгалә моны "Йосыф" сүрәсендә ача.

Нәфеснең дусты шайтан да шул ук максатларны күз алдында тота. Коръәни-Кәримдә шайтанның безнең ачык дошманыбыз булуы турында әйтелә: **"Ий, Адәм балалары, Мин сезгә гаһед кылмадыммы һәм бердермәдемме шайтанга гыйбадәт кылмагыз, вә аның сүзе белән йөрмәгез, әлбәттә, ул сезгә ачык дошмандыр. Сез Миңа гына гыйбадәт кылыгыз, Миңа гына гыйбадәт кылу һәм мин күрсәткән юлдан гына бару - шулдыр туры юл, дип әйтмәдеммени? *(Йәсин" сүрәсе, 60,61 нче аятьләр).***

Бу турыда Имам Бусайри үзенең бер хезмәтендә болай ди: "Нәфес белән шайтан артыннан барырга уйлама. Алар сине бик яхшы үгетләрләр. Яхшылыкка өндиләр, дип уйлый башласаң да, барыбер алар турындагы фикереңне үзгәртмә".

Кешенең йөрәге һәрвакыт нәрсәдер ишетә. Моның фәрештәләрдән дә, шайтаннан да булу ихтималын белеп тор. Әгәр дә тавыш начарлыкка (аны яхшылык итеп күрсәтеп) өнди икән, бу - шайтаннан, син аннан ерак торырга тиеш. Әгәр дә ул яхшы гамәлләр кылырга чакыра икән, моның фәрештәдән булуын бел. Бу гамәлне кичектермичә кылырга тырыш һәм Аллаһы тәгаләгә шөкер ит.

Рәхмәтле кеше - фикер йөртүче кеше, фикер йөртүче кеше - һәрвакыт Аллаһы тәгаләне искә алучы кеше. Аллаһы тәгаләне искә алып торучы кеше шайтаннан ерак, фәрештәләргә якын торыр, үзен игелекле эшләр кылуга өйрәтер. Шулай итеп, гөнаһларыннан котылыр һәм игелекле эшләр санын арттырыр. Киресенчә, фәрештәләрдән ерак торучы кешенең дусты шайтан булыр. Аңа гөнаһ кылу гадәтеннән котылу кыен.

Кеше гөнаһлары ике төргә бүленә: кече һәм олы гөнаһлар. Гөнаһ кылган өчен җәза аның зурлыгына бәйле. Олы гөнаһлар булып түбәндәгеләр исәпләнә:

Аллаһы тәгаләгә тиңдәш кылу;
әти-әнигә каршы бару;
ялган шаһитлык итү;
көрәш кырыннан качу;.
башка кешенең намусына тап төшерү;
урлау.

Нииндидер гамәл кылу сәбәпле йөрәгебез тынычсыз икән, без моны башкалар белер дип куркабыз икән, бу очракта сүз кече гөнаһлар турында бара. Алардан читләшергә кирәк. Шикле нәрсәләрдән сакланырга кушып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: "Шикле нәрсәләрне, алардан котылганчы, калдырыгыз". Күпсанлы һәм азсанлы, олы һәм кече, яшерен һәм ачык гөнаһлардан сакланырга кирәк. Кечкенә ташлардан таучык ясалган кебек, кече гөнаһлар җыелып зур гөнаһ ясыйлар. Бу турыда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм хәдисендә болай ди:

"Кече гөнаһларны һәрдаим кылып торсаң, алар элеккечә кече булып калмыйлар. Әгәр дә чын күңелдән Аллаһы тәгаләдән олы гөнаһларны кичерүен сорасаң, алар гафу ителәчәк".

Бервакыт Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм бер агач та үсмәгән чүлдә булганда, үзенең сахабәләреннән утын җыюларын сорый. Сахабәләр бередә бернинди дә утын күрмәүләрен әйтәләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай ди: "Зурлыкларына карамыйча, бөтен нәрсәне җыегыз, иң кечкенә ботакларны да калдырмагыз".

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм сахабәләре юлларында очраган бөтен нәрсәне җыеп алып киләләр, шактый зур күч җыела. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм, җыелган чүп өеменә күрсәтеп, болай ди: "Яхшылык белән яманлык та менә бу күчкә охшаган. Кечкенә нәрсәләрне бергә җыйгач, зур әйбер хасил була".

Аллаһы тәгалә колы өчен кайбер гөнаһлар кечкенә булып күренергә мөмкин, ләкин Аллаһы тәгалә өчен алар зур була. Кеше кылган гөнаһын кечкенә дип уйларга тиеш түгел, ә аның өчен Аллаһы тәгалә алдында ничек җавап тотачагы турында уйларга тиеш. Аның бөеклеге турында уйлап, яхшы якка үзгәрергә тырышырга кирәк.


Хөрмәтле дин кардәшләрем!

Гөнаһлар - Аллаһы тәгалә белән синең арада күтәрелгән дивар ташлары сыман. Бу ташлар, үзләре кечкенә булуларына карамастан, бергә җыйгач, зур дивар хасил иткән. Шулай ук гөнаһлар да, җыелып, Аллаһы тәгалә белән Аның колы арасында әйләнеп үтә алмаслык биек дивар булып күтәрелә. Тәүбә итү - бу дивар ташларын эретә алырлык нәрсә.

Башкача әйткәндә, гөнаһ - мөселман кешесенең җанын җәзалаучы кием кебек. Гөнаһлы кеше өчен гөнаһ җәйсыз, кысан, ямьсез һәм ятрап кимәгән кием сыман. Ул кылган гөнаһны башкалар күрмәсәләр дә, моның өчен аны оялтмасалар да, хөкемнән кача алса да, эченнән нәрсәдер һәрвакыт борчып торачак. Шуңа күрә гөнаһ - җәйсыз кием булса, тәүбә - бу киемне салырга мөмкинлек бирә. Тәүбә ләззәт һәм рәхәтлек бирүче кием сыман.

Бөек Сухейх хәзрәт тәүбә турында болай ди: "Үкенү - тискәре якларны уңай якларга алыштыру". "Үкенү сүзләрдә генә булырга тиеш түгел, начар сыйфатлардан котылу һәм аларга беркайчан да кире кайтмау нияте булырга тиеш". Бу турыда Аллаһы тәгалә Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай ди: "Тәүбә - зур үкенү". Тәүбә итмәүче кешенең йөрәге тора-бара кара гөнаһ таплары белән каплана. Әгәр дә бу тапларга игътибар бирмәсәң, тәүбә белән юмасаң, алар калын рухи пычрак

***Кешенең йөрәге һәрвакыт нәрсәдер ишетә. Моның фәрештәләрдән дә, шайтаннан да булу ихтималын белеп тор. Әгәр дә тавыш начарлыкка (аны яхшылык итеп күрсәтеп) өнди икән, бу - шайтаннан, син аннан ерак торырга тиеш. Әгәр дә ул яхшы гамәлләр кылырга чакыра икән, моның фәрештәдән булуын бел. Бу гамәлне кичектермичә кылырга тырыш һәм Аллаһы тәгаләгә шөкер ит.***



# Иң камил тәүбә догасы

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең мондый сүзләре бар: "Дога белән Аллаһыга ялварган кеше өчнең берсен алыр: ул сораганнар я аңа шунда ук ирешер, яки аның бу догасы кабул ителеп, гөнаһлары ярлыканыр, яисә ул бу догасына ахирәттәге торомышында әҗерен алыр".

Шәдад ибне Әвс җиткерә ки, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм хәдисендә болай диелә: "Иң камил тәүбә догасы - Аллаһы колы Яралтучысына түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итсә: **"Аллаһуммә әнтә Рабби, лә иләһә иллә әнтә халәктани үә ана габдук, үә ана галә гаһдикә вә вагъдикә мастагту. Әгузе бикә мин шарри мә санагту, әбүү ләкә би-нигъмәтикә галәйә, вә әбү бизанби фәгъфир лии, фа-иннәһү лә йәгъфирүз-зунуба иллә антә"**. *Мәгънәсе: Аллаһым! Син минем Раббым. Синнән гайре гыйбадәт кылырга лаеклы башка иләһ юк. Син мине яралттың. Мин синең колың. Мин хәлемнән килгәнчә Сиңа тугры һәм итагатьле булырга дигән антыма тугры калырга тырышам. Кылган гөнаһ вә ялгышлыкларымнан бер Сиңа гына сыгынам. Биргән барча нигъмәтләреңә рәхмәтлемен, кылган гөнаһларымны гафу итүеңне сорыйм! Ирештер миңа ярлыкавыңны, чөнки Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы башка беркем дә юк".*

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм бу доганы **"иң төп тәүбә догасы"** дип атаган, чөнки аның эчтәлеге бар тәүбә догаларын да үз эченә ала. Бу догага салынган тирән мәгънә аркасында аны "сәйидел-истигъфар" - "тәүбә догаларының башлыгы" дип атыйлар.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: "Бу доганы кем дә булса ихластан, аның көче һәм әһәмиятенә чын күңелдән ышанып көндез укыса һәм кич җиткәнгә кадәр вафат булса - ул җәннәткә керер. Ә аны ихластан, аның көче һәм әһәмиятенә чын күңелдән ышанып кем дә булса төнлә укыса һәм иртә җиткәнче вафат булса - ул да җәннәткә керер" (Бохари. Дәгъвәт, 2,16; Әбү Дауд. Әдәб, 100-101; Тирмизи, Дәгъвәт, 15; Нәсаи, Истигазә, 57).



катламына әверелә. Һәрвакыт янып торган, бер дә чистартылмаган лампа корым белән каплангач, яктылык бирмәгән кебек, гөнаһлы кешенең йөрәге дә хакыйкатьне күрми башлый. Ахырда ул хәсрәткә бата, чөнки гөнаһ кайгыларны тартып китерә.

Кеше башына төшкән кайгыларның сәбәбе ул кешенең үзендә. Күпсанлы кыенлыклар - кеше гамәлләренең нәтиҗәсе. Аллаһы тәгалә болай ди: **"Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһыдан, әгәр казадан бер кайгы ирешсә, бу кайгы үзеңнең**

***Мөселманнар өчен тәүбәдә зур файда бар. Хәдисләрнең берсендә болай диелә: "Аллаһы тәгалә ризалыгына китерүче тәүбә итүдән дә зуррак гыйбадәт юк".***

**кимчелегеңнәндер. Янә сине, ий, Мөхәммәд галәйһиссәлам, бөтен дөнья кешеләренә ислам динен өйрәтер өчен илче итеп җибәрдек. Кешеләрнең бөтен эшләрен күреп, белеп торырга Аллаһ үзе җитәдер.".** ***("Ниса" сүрәсе, 79 нче аять).***

Бер ислам дине галиме болай дигән: "Әгәр дә күңелеңдә авырлык тойсаң, тормышыңда кыенлыклар тынычлык бирмәсә, ә үткәнең синең өчен авыр йөк сыман булса, Аллаһы тәгалә боерганнарны онытып, нәфесең артыннан киткәнеңне бел. Кайгың нинди генә булмасын, аның сәбәбе булуын онытма, ялгышларыңны төзәтергә тырыш. Әгәр дә йөрәгеңдә үзең аңлый алмаган авыр кичерешләр һәм газап булу сәбәпле төшенкелек һәм өметсезлек тоясың икән, моннан Аллаһы тәгалә күрсәтмәләрен үтәп кенә котылып буласын аңла. Кичекмәстән хаталарыңны төзәтергә тырыш.

Чөн мөэминнәр бу сорауга зур җаваплылык белән карыйлар. Үз гөнаһларын алар өсләренә ишелеп төшәргә әзер зур тау итеп күрәләр. Курку һәм үкенү хисләре кичерәләр. Ә гыйбадәт кылуда хилафлык күрсәтүчеләр исә кылган гөнаһларын борыннарына бер мизгелгә генә кунып, очып киткән черки сыман кечкенә нәрсә итеп күрәләр. Бу бик зур ялгышу".

Тән авыруларының сәбәбе булган кебек, йөрәк һәм җан авыруларының да сәбәбе бар. Бу Аллаһы тәгалә һәм Аның Илчесе саллаллаһу галәйһи үә сәлләм тыйганнардан тыелмау. Бу авырудан котылу өчен бөтен кимчелекләрне калдырырга кирәк, кечеләрен дә, олыларын да.

Моңа кадәр без кешенең идеаль һәм гөнаһсыз була алмавы турында сөйләдек. Гөнаһыңны белеп, аның булуын кире какмау да яхшы сыйфат. Бу да билгеле бер дәрәҗәдә үкенү булып исәпләнә, димәк, кешене киләчәк тормышка әзерләргә булыша. Исән чагында киләчәк тормышка әзерләнмәгән кеше кылганнарына игътибар бирми һәм алга таба бик нык үкенәчәк. Бу үкенү бернинди дә файда китерми, ләкин бу чын үкенү булачак.

Үкенүнең дүрт төрле булуы билгеле:

1. Көндәлек үкенү. Мондый үкенү кылган хатадан соң аны төзәтү мөмкинлеге бирә, яки бу хатаның зыяны бер көннән артыкка сузылмый.

2. Еллык үкенү. Кылган хатаның нәтиҗәсеннән бары тик бер ел эчендә генә котылып була. Үкенү бер елга сузылса да, нәтиҗәдә ул узачак.

3. Гомерлек үкенү. Бу үкенү кешегә гомере буе тынычлык бирмәячәк. Соңгы сулышына кадәр кешенең җанын газаплаячак. Ләкин бу үкенү үлем белән китәчәк.

4. Мәңгелек үкенү. Аллаһы тәгалә барыбызны да бу үкенүдән сакласын. Бу беркайчан да үкенмәгән, тәүбә итмәгән, Аллаһы тәгаләгә ышанырга өлгермәгән, кинәт үлеп киткән кеше үкенүе. Бу үкенүне төзәтеп булмый.

Аллаһы тәгалә безне бу дүрт төрле үкенүдән дә сакласын иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм бер хәдисендә болай дигән:

"Сезне җавапка тартканчы үзегезне үзегез хөкем итегез". Һәм без бу сүзләргә колак салырга, үкенергә, тәүбә итәргә һәм гафу сорарга тиеш.

Биш нәрсәне кылуда ашыгу - үз тормышыңның хуҗасы булырга мөмкинлек бирә. Бу биш нәрсәне безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм ача:

1. Кызыңны кияүгә бирүдә ашыгу.
2. Сәфәрдә булучыны хөрмәтләү.
3. Үлгән кешене җирләү.
4. Бурычны түләү.
5. Тәүбә итүдә ашыгу.

Шулай ук: "Намаз вакыты чыкканчы намаз укырга, үлем килгәнче тәүбә итәргә ашыгыгыз".

Шуңа күрә кеше тормышында тәүбә итүдән дә җаваплы гамәл юк. Тәүбә итүне һәм кичерүне сорауны киләчәккә калдыру, кичектерү - наданлык. Бу җәзага, рухи үлемгә риза булу.

Үлемгә һәрвакыт әзер булырга кирәк, Аллаһы тәгаләнең ризалыгына ирешергә, яхшы гамәлләр кылырга, Аллаһы тәгалә ризалыгына ирешер өчен тагын бер тормыш булмавын белергә, үлем безгә теләсә кайчан килә алуын онытмаска кирәк.

Без ахирәттәге тормышка әзерлек бу дөньяда булуын белергә тиешбез. Кирәк булган әйберне бу дөньяда да шул ук мизгелдә алып булмый, яхшы гамәлләр генә исәпләнгән ахирәт турында нәрсә әйтәсең инде. Аларны алдан ук әзерләп куярга кирәк. Төнлә та-

***Тәүбә итмәүче кешенең йөрәге тора-бара кара гөнаһ таплары белән каплана. Әгәр дә бу тапларга игътибар бирмәсәң, тәүбә белән юмасаң, алар калын рухи пычрак катламына әверелә. Һәрвакыт янып торган, бер дә чистартылмаган лампа корым белән каплангач, яктылык бирмәгән кебек, гөнаһлы кешенең йөрәге дә хакыйкатьне күрми башлый.***

ныш булмаган, караңгы юлдан барганда артыбыздан яктыртучы ут безгә булыша алмый, ул бездән алда булырга тиеш. Шулай ук ахирәттә дә юлны яхшы гамәлләребез нуры яктырта. Иң әүвәл тәүбә итәргә кирәк. Тәүбә итүнең беренче баскычы - үкенү, кылган гөнаһларга үкенү. Аллаһы тәгаләнең мөселманнарга тәүбә итәргә кушуы - Аның шәфкате. Аятьләрнең берсендә бу темага болай диелә: "Ий, мөэминнәр, һәммәгез дә Аллаһыга тәүбә итегез, шаять, дөнья вә ахирәттә бәхетле булырсыз". ("Нур" сүрәсе, 31 нче аять). Бу аятьтә Аллаһы тәгалә гөнаһларны танып, тәүбә итүне мөселманнар өчен мәҗбүри дип куя.

Тәүбә итүне кичектерү ярамый. Гөнаһ кылып, үкенү, тәүбә итүне кичектерү - үзе гөнаһ. Бу турыда Аллаһы тәгалә Илчесе саллаллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: "Аллаһы тәгаләдән гөнаһларыгызны кичерүен сорагыз (тәүбә итегез). Чөнки мин дә көн саен йөз тапкыр Аллаһы тәгаләдән кичерүен сорыйм".

Мөселманнар өчен тәүбәдә зур файда бар. Хәдисләрнең берсендә болай диелә: "Аллаһы тәгалә ризалыгына китерүче тәүбә итүдән дә зуррак 31 нче гыйбадәт юк". Әйе, Аллаһы тәгалә мөселманнарга да, мөселман булмаучыларга да кичерүен сорарга куша. Аның шәфкатенә өметләнүебезне тели. Чөнки Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы тәгалә бер аятьтә болай ди:

**"Аллаһ үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны үзе теләгән кешедән гафу итәр. Бер кеше Аллаһыга кемнедер, нәрсәнедер тиңдәш кылса, дөреслектә, ул Аллаһыга олы ялганны ифтира кылган буладыр. ("Ниса" сүрәсе, 48 нче аять). Икенче бер аятьтә болай диелә: "Аллаһы тәгалә, әлбәттә, үзенә тиңдәшлек кылуны ярлыкамас, мәгәр тиңдәшлек кылу гөнаһыннан башка гөнаһны үзе теләгән кешедән ярлыкар. Берәү кемнедер, нәрсәнедер Аллаһыга тиңдәш кылса, ул кеше хактан бик ерак адашу белән адашты"** ***("Ниса" сүрәсе, 116 нчы аять).***

Бөек мөселман фикер иясе Мәүләнә Җәләлетдин Руминың бик матур сүзләре бар: "Кайт, яңадан кайт. Йөз тапкыр сүзеңдә тормаган булсаң да, барыбер кайт. Потларга гыйбадәт кылырга киткән булсаң, барыбер кайт. Чөнки безнең диндә котылгысызлык юк".


Хәдисләрнең берсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай ди: "Аллаһы тәгаләгә Аның шәфкатенә өметен югалтмаган җинаятьче өметен югалткан гыйбадәт кылучыга караганда якынрак".

Тәүбә итү - башка гөнаһ кылмаска сүз бирү. Һәм бу килешүне кеше гөнаһка кире кайтмау нияте белән сакларга тиеш. Аллаһы тәгалә безне олы һәм кече гөнаһлардан сакласын. Аллаһы тәгалә - барыбызны да кичерүче. Ул безне Үзенең шәфкатенә лаек булучылар арасына кертсен иде. Амин.

*Татарстан Республикасы мөфтие*
*Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН*

# Могҗиза китерүне сорау

**Укучыларыбыз игътибарына күренекле дин галиме Сөнгатулла БИКБУЛАТОВның "ХӘЗРӘТИ МӨХӘММӘД" китабыннан өзекләр тәкъдим итәбез. Моннан тыш аның тагын "Мәбдә әл-кыйраәт", "Дин дәресләре", "Мәбдә ән-нәхү", "Дүрт хәлифә", "Әбү Бәкер вә Гомәр дәвере" дигән зур хезмәтләре бар.**




Рәсүлуллаһ, мәккәлеләрнең иза вә җәфа кылуларына карамастан, үз өстенә йөкләнгән вазыйфасын үтәүне дәвам итте. Ул берсе артыннан берсе иңеп торган Коръән-Кәрим аятьләрен (теләсәләр дә, теләмәсәләр дә) боларның мәҗлесләренә килеп укый иде. Коръән-Кәрим аларны төрле юллар белән тәүхидкә, Кыямәт көненә ышанырга, изге гамәлләр кылырга, потларын ташларга һәм аларны арадашчы итеп куймаска, араларында таралган начар гадәт һәм әхлактан арынырга чакыра иде, төрле дәлилләр белән Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлеген исбат итә иде. Кайбер вакытта турыдан-туры кисәтүләр яудыра иде. Матур сөйләмнең иң югары дәрәҗәсендә булган Коръән-Кәрим матур сөйләмгә сәләтләре булган гарәпләргә гадәттән тыш нык тәэсир итә иде. Алар моңа каршы ни эшләргә дә белми иде. Рәсүлуллаһка мәҗнүн, каһин, шагыйрь, сихерче кебек ифтиралар әйтсәләр дә, бу - үзләрен алдау яки үзләрен юату гына иде. Чөнки мәҗнүннән андый сүзләр чыга алмаганын, каһиннәрнең дә күрәзәлек кылу кебек нәрсәләр генә булганлыгын, Мөхәммәд галәйһиссәлам моңа кадәр, асылда, шигырь белән шөгыльләнмәгәнгә, кинәт шагыйрь була алмаганын, аның өстенә Коръәннең шигырьгә бер дә охшамаганлыгын һәм чагыштырып та булмаслык өстен икәнлеген алар бик яхшы белә иде.

Алар рәсүлуллаһны бигрәк тә "сихерче" диде. Китергән дәлилләре дә: атадан - баланы, баладан атаны аерып алып, үзенә ияртү иде. Ләкин бу да - күз буяу гына, моңа каршы башка юл таба алмаганлыктан гына мәҗбүри әйтелә иде. Аның сихер түгеллеген дә алар бик яхшы белә иде.

Гарәпләр рәсүлуллаһның фәрештә булмыйча, үзләре кебек бер кеше булып, аның базарларда сәүдә итеп йөрүен, ашау-эчүен пәйгамбәрлеккә шөбһә итеп китерә иде[1].

Ләкин бу да ни әйтергә белмәгәннән генә әйтелгән сүзләр иде. Чөнки алар, үзләре үк, кайвакыт: "Бу Коръән зуррак бер кешегә килгән булса, без аны кабул итәр идек", - дип тә әйтә иде[2].

Нәтиҗәдә, гарәпләр Коръән-Кәримгә карата бик нык аптырашта калды һәм алар башларына ни килсә шуны әйтә иде. Мәсәлән: "Коръән ул - әүвәлгеләрдән калган әкият, Мөхәммәд аны башкалардан өйрәнде", - дип тә әйтә иделәр[3].

Коръән-Кәрим боларның шушы шөбһәләрен төрле-төрлеысуллар белән инкарь итә, рәсүл булу өчен фәрештә булу кирәк түгеллеген, фәрештә рәсүл итеп җибәрелгәндә дә - кеше сурәтендә булуы зарури булып, һаман шул ук шөбһәләрне китерәчәкләрен, Мөхәммәд саллаллаһу гәләйһи үә сәлләмнән башка илчеләр дә аның кебек кеше булып, ашый, эчә, базарларга йөри торганлыкларын, рәсүл булу өчен дәрәҗәле һәм мәртәбәле булу шарт түгеллеген сөйли, рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген исбат итү өчен Коръән-Кәримне дәлил итеп тотарга, аларны шул Коръән белән чакырырга, Коръән кебек бер сүрә, ниһаять, бер генә аять китерүләрен сорарга әмер итә иде һәм китерә алмаячакларын алдан ук әйтеп куярга куша иде. "Әл-Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 23 һәм 24 нче аятьләрендә килгән кебек каршы чыккан аятьләр берничә җирдә бардыр.

Ләкин бу вакытларда гарәпләр әдәбиятта бик каты алга киткән, матур сөйләмдә алдынгылардан булган, араларында авызларыннан ут чәчә торган хатыйбләр, акылны үзенә буйсындыра торган шагыйрьләре була торып, Коръән шикелле китап яза алмадылар, гаҗиз калдылар. Тик җавапсыз калмас өчен: "Бу - борынгылар хакындагы әкиятләрдән гыйбарәт. Без, теләсәк, моның кебек нәрсәләрне сөйләр идек, әмма теләмибез генә",- дип әйттеләр. Шунлыктан алар Коръәннең кеше сүзе булмыйча, Аллаһы сүзе икәнен белсә дә, инкарь һәм карышу юлына кереп, рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген кабул итмәде. Ялгыз, хакыйкать күзе белән карый торган акыл ияләре әкрен-әкрен генә исламга керә торды. Әмма күпчелек, әүвәлге юлларында дәвам итеп, кирелек, тәкәбберлек белән каршы килә иде.

Корәеш гарәпләре, рәсүлуллаһны һәм күркәм сахабәләрне рәнҗетү һәм газаплау белән генә диннән чыгара алмаганнарын аңлап, киресенчә, бу эшләр ислам әһелләренең дингә карата мөнәсәбәтләрен тагы да ныгытканлыктан, эшне икенче юл белән йөртмәкче булды. Бу хакта бер киңәш мәҗлесе ясап, Гутбә бине Рабиганың фикере белән, Мөхәммәд галәйһиссәламне яңа дин оештырудан туктатыр өчен түбәндәге мәсьәләләрне ачыкларга булдылар:

1) Мөхәммәднең бу эштә максаты мал җыю булса, аңа мал җыеп бирергә;

2) әгәр сәид буласы килсә, аны сәид итеп куярга, аңардан башка һичбер мәсьәләне хәл кылмаска;

3) әгәр патша буласы килсә, үзләренә патша ясарга;

4) әгәр бу эш җен кагылу кебек берәр сәбәптән килсә, аны табиблар чакырып дәваларга.

Ошбу мәсьәләне ачыклар өчен, Гутбә бине Рабиганы җибәрделәр. Гутбә, рәсүлуллаһка барып: "Әй, Мөхәммәд, син безнең арада хөрмәтле бер кеше идең, син бу эшең белән кавемеңнең арасын боздың, аларны бер-берсеннән аердың, аларның акылларын ахмаклыкка чыгардың, потларын кимсеттең, ата-бабаларын томаналык һәм адашуда гаепләдең, синең бу эшеңнең максаты нәрсә? Әгәр максатың мал җыю булса..." - диде. Гутбә сүзен сөйләп бетергәч, рәсүлуллаһ: "Инде сүзең беттеме? Моны миннән ишет инде!" - дип, "Фүссыйләт (Аңлатылды)" сүрәсенең башыннан берничә аять укыды. Бик аңлаешлы һәм гаҗәп Коръән аятьләрен ишетеп, Гутбә бик нык тәэсирләнде. Чыдый алмыйча, рәсүлуллаһның авызыннан тотып туктатты. Соңра, кавеменә кайтып, ошбу сүзләрне сөйләде: "Мин Мөхәммәдтән шундый сүзләр ишеттем, аның шикелле сүзләрне гомеремдә дә ишеткәнем юк иде. Ул - шигырь дә түгел, багучылык-күрәзәчелек тә түгел, сихер дә түгел. Мин сездән Мөхәммәдне үз юлына куюыгызны, аны изаламавыгызны үтенәм! Әгәр Мөхәммәд өскә чыкса, ул сезнең өчен бик шәриф булачак. Әгәр башка кабиләләр кулы белән җиңелсә, мәшәкатьсез сез аннан котыласыз!" - диде.

Гутбәнең бу сүзләрен ишеткәч, мөшрикләр: "Мөхәммәд сине дә сихерләгән икән", - диде. Аларга каршы Гутбә: "Бу - минем үземнең шәхси фикерем, кабул итсәгез - итегез, итмәсәгез - итмәгез", - диде.

> ***Бик аңлаешлы һәм гаҗәп Коръән аятьләрен ишетеп, Гутбә бик нык тәэсирләнде. Чыдый алмыйча, рәсүлуллаһның авызыннан тотып туктатты. Соңра, кавеменә кайтып, ошбу сүзләрне сөйләде: "Мин Мөхәммәдтән шундый сүзләр ишеттем, аның шикелле сүзләрне гомеремдә дә ишеткәнем юк иде. Ул - шигырь дә түгел, багучылык-күрәзәчелек тә түгел, сихер дә түгел. Мин сездән Мөхәммәдне үз юлына куюыгызны, аны изаламавыгызны үтенәм!***

# Коръәннән үзләренә ошамаган сүзләрне алып ташлауны үтенүләре

Моннан соң Корәеш гарәпләре Мөхәммәд галәйһиссәламнән сүзләрен йомшартуны, Коръәндәге сыннарны яманлаган, потларын кимсеткән, газап белән куркыткан аятьләрне чыгаруны, шулай ук аларның ачуларын китерә торган, нәфрәтләрен арттыра торган аятьләрне укымауларын үтенде. Әмма бу таләпләренең барысы да буш бер нәрсә иде. Чөнки Коръән, рәсүлуллаһның үзе тарафыннан әйтелгән бер сүз булмыйча, Аллаһы тәгалә тарафыннан иңдерелгән иде. Рәсүлуллаһ моны җиткерергә мәҗбүр булган хәлдә, һәм шуңа нигезләнеп, аны үзгәртүе мөмкин түгел иде. Шуңа күрә дә, моңа каршы, Аллаһы тәгалә рәсүлуллаһка аларга ошбу сүзләр белән җавап бирергә әмер итте: **"Син аларга әйт: "Үзлегемнән аны (Коръәнне) алыштыру миңа мөмкин түгел. Мин бары тик миңа иңгән вәхи артыннан гына иярәм..." ("Йунус" сүрәсе, 15 нче аять) һәм "Әгәр ул (Мөхәммәд галәйһиссәлам) Безнең әйтмәгән бәгъзе сүзне Аллаһыдан дип ялганлап сөйләсә, әлбәттә, без аны каты тоту илә тотар идек. Соңрак аның йөрәк тамырларын кисеп алыр идек"** ***("Әл-Хакка (Котылгысыз)" сүрәсе, 44-46 нче аятьләр).***

Рәсүлуллаһ белән һичничек килешү мөмкин булмагач, җәбер вә изалау белән дә аны туктатырга тырышу нәтиҗәсез булгач, аңардан, үзенең рәсүлуллаһ икәнлегенә дәлил итеп, могҗизалар күрсәтүен сорадылар. Алар: "Мөхәммәд, әгәр син пәйгамбәр булсаң, башка пәйгамбәрләр кебек дәлилләр һәм могҗизалар китер, без синең бу Коръәнеңә генә ышана алмыйбыз", - диделәр. Боларның нәрсәләр һәм нинди юллар белән таләп иткәнлекләре Коръән-Кәримдә бик күп сүрәләрдә искә алына. Алар рәсүлдән Гарәбстан сахраларында чишмәләр агызуын, эчләрендә елгалар агып яткан хөрмә һәм йөзем бакчалары булдыруын, үзенә алтын вә көмеш өйләр булдыруын, Хиҗаз тауларын күтәреп ташлап, җирне тигез итеп ясавын, күккә менеп, үзенең пәйгамбәрлеге хакында язу алып төшүен, фәрештәләр алып килеп, үзенең рәсүллеген тәсдыйк итүен, Кусай бине Кыләб кебек, бабаларын терелтеп, шулардан пәйгамбәрлеген исбатлатуын һәм моннан башка да күп нәрсәләр сорадылар . Әмма, боларның могҗизалар таләп итүләре - Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә китергән дәлилләренә канәгать хасыйл итмәгәннән булмыйча, бары тик үзләренең кирелегеннән һәм рәсүлуллаһны җавапсыз калдырырга тырышудан гына иде һәм могҗизалар күрсәтелгәндә дә кабул итмәячәкләр иде. Шуның өчен Аллаһы тәгалә боларга сораган нәрсәләрен бирмәде, ә киресенчә, "Әйт син аларга: "Сөбханаллаһ, мин бит сезнең кебек бер кеше генә, миндә андый нәрсәләргә кодрәт юк" ("Әл-Исра (Төнге күчерү)" сүрәсе, 93 нче аять) ; "Сез беләсезме соң, аларның таләп иткән дәлилләре бирелгәндә дә иман китермәүләрен?" ("Әл-Әнгам (Мал-туар)" сүрәсе, 109 нчы аять); "Без сиңа иңдергән китап могҗиза булырга җитмиме инде аларга?!" ("Әл-Ганкәбут (Үрмәкүч)" сүрәсе, 51 нче аять); "Синең пәйгамбәрлегеңне Бәни Исраил галимнәре белү аларга дәлил була алмыймы?" ("Әш-Шугара (Шагыйрьләр)" сүрәсе, 194 нче аять) кебек аятьләр белән җавап бирергә кушты. Корәеш гарәпләренең сораганнары бирелсә дә, алар кабул итмәячәкләреннән, Аллаһы сөннәте буенча аларның һәлак ителүләре максат түгеллеген "Без аларга могҗизаларны җибәрмәдек, чөнки алдан килгәннәр аларга инанмады" ("Әл-Исра (Төнге күчерү)" сүрәсе, 59 нчы аять) кебек аятьләр белән җавап бирде.

---

[1] һәм алар әйтте: "Бу нинди рәсүл? Ул ризык ашый, базарларга йөри..." ("әл-Фуркан (Аергыч)" сүрәсе, 7 нче аять) - **Авт.**

[2] һәм алар тагы әйтте: "Ни өчен бу Коръән ике шәһәрнең олуг бер ир-атына иңдерелмәде?" ("әз-Зухруф (Бизәнүләр)" сүрәсе, 31 нче аять). Тәфсир кылучы галимнәрнең сүзләренә карап, бу ике шәһәр - Мәккә белән Таиф булыр, ә олуг кеше - Вәлид бине әл-Мугыйра белән Гарвә бине Мәсгуд әс-Сәкафиләрдер - **Авт.**

[3] Имансызлар әйтте: "Бу - башка кавемнәр ярдәмендә уйлап кына чыгарган алдау". Чынлыкта исә, алар золымлык кыла һәм ялганлый" ("әл-Фуркан" сүрәсе, 4 нче аять). Тәхкыйк, без беләбез: "Чынлыкта исә, аны кеше генә өйрәтә". Алар ишарә иткән тел - чит телдер. Ә бу - аңлаешлы булган гарәп теледер" ("ән-Нәхел (Бал кортлары)" сүрәсе, 103 нче аять).

Һәм алар әйтте: "Ул - әүвәлге өммәтләрнең уйдырмасыдыр. Ул аны күчереп яздырды һәм аңа иртәләрен һәм кичләрен укыйлардыр" ("әл-Фуркан (Аергыч)" сүрәсе, 5 нче аять) - **Авт.**

# "СИН ҖИҢГӘНСЕҢ ТУГРЫ ДИН БЕЛӘН..."

**"Дин вә мәгыйшәт"нең ноябрь санында Мәүлид бәйрәме уңаеннан Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмгә багышланган шигырьләр конкурсы игълан иткән идек.**

Бер кочак шигырьләр арасыннан уңышлы саналганнарын газетабызның узган санында бастырып та чыгардык. Хөрмәтле шагыйрьләребез-шагыйрәләребез! Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, "Хузур" нәшрият йорты һәм "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе коллективы адресына әйткән җылы сүзләрегезгә, изге теләкләрегезгә без чиксез шатбыз. Ә инде ихлас шигырьләрегез белән сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмне зурлавыгыз өчен сезгә Аллаһының рәхмәтләре ирешсен.

Шулай итеп бәйгебезнең җиңүчеләрен игълан итәбез. Болар - Казаннан Рифат Сәлахов, Чүпрәледән Сания Шәрәпова һәм Әгерҗедән Асия Корбангалиева. Шулай ук Казаннан Нурфия Халикова, Әгерҗе районы Кичкетаң авылыннан Рәмзия Җиһангәрәева, Яңа Чишмә районы Акбүре авылыннан Рамилә Вәлиуллина, Казаннан Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Яшел Үзән районы Бишнә авылыннаннан Сөмбелә Абдуллина, Кама Тамагы районы Балчыклы авылыннан Ләйсән Сәгъдиева, Казанның Вознесение бистәсеннән Камил Рамазановларның шигырьләрен дә бик яратып укыдык. Һәрбарчагызга Аллаһы Раббыбыз саулык-сәламәтлек, хәерле гыйлемнәр алып, саваплы гамәлләр кылып яшәүләрне насыйп итсен. Бәйгегә нокта куеп, күчтәнәчкә тагын бер шигырь тәкъдим итәбез.



*Рифат СӘЛАХ*

## *Пәйгамбәргә*

Хакыйкатькә һәрчак
каршы гавам,
Хакыйкатькә куеп авызлык
Күп кешеләр яшәмәкче була,
Эстәп ләззәт, кылып явызлык.

Үз-үзләрен илаһ итеп тоеп
Яшәп яткан чакта адәмнәр.
Син тугансың, газиз Рәсүлуллаһ,
Аллаһыдан килгән пәйгамбәр.

Үз кавемең сиңа Әмин дигән,
Аннан мәҗнүн диеп атаган...
Дошмандыр шул,
итагатьле булып,
Куркып яшәүчеләр Алладан.

"Үтерергә!" - дигән Иблис үзе,
Кылыч биргән кырык егеткә.
Аллаһ кушса,
Сиңа зыян тими,
Дошманнарың сине күреп тә.

Син җиңгәнсең!
Кылыч белән түгел,
Хакыйкать һәм тугры дин белән.
...Исемеңне искә алган саен
Күз яшьләре чыга... күңелдән.

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ҮӘ СӘЛЛӘМНЕҢ ӘХЛАГЫ ҺӘМ ТОРМЫШ ЮЛЫ

**"Галәмнәрнең горурлыгы" Әфәндебез хәзрәтләре урта буйлы, бодай төсле, йөзе гүзәл, ачык һәм нурлы, сирәк сакаллы, бик мәхәббәтле, йомшак һәм сабырлы иде. Әшәкелек сөйләмәс, гаепләмәс, дәрәҗәсеннән артык һич нәрсәне кертмәс, халыклар гаҗәп итә торган нәрсәләрдән хәйран итәр һәм елмаеп, фәкать кычкырып көлми иде.**

Халыклар дөнья сүзе сөйләгәннәрдән алар белән дөнья сүзе һәм ахирәт сүзе сөйләгәннәреннән ахирәт сүзе сөйләр иде. Бик юмарт булганга күрә, сораучыларга һич вакыт "юк!" димәс, милкендә динар һәм дирһәм булган хәлендә бер төн чыкмас, сәдака малы ашамас, бүләкләрне кире кайтарыр. Бер кеше килеп күрешкән вакытта ул кеше кулын алмады, чөнки кулында зөбәрҗәт иде. Күбрәк ашы хөрмә белән су булып, фәкать бер вакытта да туярлык итеп ашамады, йортында ут яндырмыйча айлар үткәрә торган була. Кыюлыгы һәм батырлыгы шул дәрәҗәдә имештер, бик көчле сугыш вакытларында иң баһадир сахабәләр Зат Шәрифәләренә сыгына торган булырлар. Кем үлсә дә үлсен, чакыручы кебек барыр, сахабәләренең бакчаларына кереп йөрер, утырган вакыт башкасы тарафына аягын сузмас, тезләнеп торганда тезләрен күршеләренең тезләреннән өзеп тормас иде. Халыкларының сүзләренә катышып сөйләр, сахабәсенең хәлләрен сорашып һәм белешеп торыр, күп киңәш алыр иде. Хәлләрен сорар өчен хасталарның яннарына барыр, читтә булганнарына хәер-дога кылыр, вафат хәбәре килсә кайгырыр һәм: "Иннә лилләһи..." укыр, истигъфар һәм дога кылыр. Бай белән ярлыны бертигез күрер, гозерне кабул итәр, туры килгән киемнәрне киер, фәкать күлмәкне сөяр, киемнәренә үзе ямау салыр, башмакларын үзе тегәр, кул тегермәне белән он тартыр, мәчеләрне ашатыр, мескеннәрне сөяр һәм алар белән һәрвакыт юлдаш булыр иде. Бик йомшак, гадәттән тыш саф һәм оялучан булып, мөмкин кадәр гафу кылыр, халыклар эшләгән вакытта карап тормас, бәлки аларга ярдәм итәр, дөясен үзе тышаулар, халыкларның алдыннан йөргәнне яратмый иде. Хатыннарына, хезмәтчеләренә, гаилә һәм артыннан баручыларга гомерендә бер тапкыр да сукмас һәм начар сүз белән эндәшмәс, яхшылык белән юрар, яман нәрсәләрдән ерак торыр, хәләлдән ни булса да ашар һәм эчәр, кабак ашын яратыр. "Сөттән артык эчемлек юк", - дип әйтә торган иде. Утырып та, аяк басып та эчәр, мөбах уеннарга каршы килмәс, урыны белән матур сөйләр. Күп вакыт дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тотар, кяферләр хакында һидәят белән дога кылыр иде.

*Ризаэддин ФӘХРЕДДИНнең "Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләм" китабыннан*

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ НИ РӘВЕШЛЕ ЮМАРТ БУЛГАН?

**Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең киеп йөргән күлмәге бик искерә, искелектән хәтта ертыла ук башлый. Ул, өендә булган дүрт дирһәм акчасын кесәсенә салып, яңа күлмәк алу өчен базарга китә.**

Күлмәк сатып ала да өенә кайта. Шуннан соң иске күлмәген салып, яңасын кигән генә була, кемнеңдер ишек шакыганы ишетелә. Ишекне ачып җибәрсә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм каршында бер фәкыйрьне күрә. Бу адәм:

- Әй Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләм, мин синең базарда яңа күлмәк сатып алганыңны күрдем. Минем күлмәгем синекеннән дә искерәк. Аллаһы ризалыгы өчен миңа шул күлмәгеңне бир әле, - дип сорый.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм күлмәген салып аңа тоттыра һәм янәдән күлмәк алу өчен базарга юнәлә. Әмма базарга барып җитә алмый. Чөнки юлда елап утыручы бер баланы күрә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм аңардан:

- Балам, нилектән күз яшеңне түгәсең? - дип сорый.

- Мин - ятим бер баламын. Минем әтием дә, әнием дә юк, шунлыктан мин бер байда коллыкта яшим. Бүген иртә белән минем хуҗам кирәк-яраклар алу өчен кулыма ике дирһәм тоттырып базарга җибәргән иде. Мин исә юлда балалар белән уйнап, ул акчаларны югалттым, шуның өчен елап утырам, - дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм кесәсендә булган ике дирһәмен чыгарып шушы балага тоттыра. Әмма нигәдер бу бала елавыннан туктамый. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм янәдән:

- Нигә елыйсың? - дип сорый.

- Хуҗам мине соңга калып бернәрсә дә ала алмаганым өчен бик каты ачуланачак. Кыйнарга да мөмкин, шуңа күрә елыйм, - дип җавап бирә ятим бала.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм, баланы җитәкләп өенә озата китә. Бу бала коллыкта яши торган йортка барып җиткәннән соң, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм ишекне шакып, каты тавыш белән: "Әссәләәмү галәйкүм", - дип әйтә. Әмма ишекне ачучы булмый. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләм өченче тапкыр каккач һәм эндәшкәч кенә ишек ачыла. Ятим баланың хуҗасыннан ул:

- Ни өчен беренче тапкыр эндәшкәч үк ишекне ачмадыгыз, әллә ишетмәдегезме? - дип сорый.

- Юк, Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам, ишетүен ишеттем. Ишекне ачмавымның сәбәбе исә синең мөбарәк тавышың минем йортымда тагы ике тапкыр яңгырасын дигән сәбәптән булды. Әй, Аллаһның Илчесе саллаллаһу галәйһи үә сәлләм, бу ятим бала синең кебек, ягъни Аллаһыга якын бер бәндә. Өемә килүгә сәбәпче булганы өчен аны колыктан азат итәм һәм үз балаларыма биргән тәрбияне аңа да бирәчәкмен дип вәгъдә итәм, - дип җавап кайтара хуҗа кеше.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Югарыда бәян кылынган вакыйганы укыганнан соң киң күңелле кешеләрнең күзләре ихтыярсыз яшь белән тула. Әлбәттә, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең кешеләргә карата миһербанлы һәм шәфкатьле булуы һич авырсынмыйча өстендәге соңгы күлмәген салып бирә алуда күренә - бу аның пәйгамбәр икәнен кат-кат дәлилли. Чыннан да, аның йөрәгендәге мәрхәмәтлелек уты Аллаһы тәгалә яралткан галәмнән дә киңрәк. Шундый шәхесләрнең исемнәре һәм тормыш үрнәкләре Кыямәт көненең ахыргы сәгатенә кадәр яшәячәк, ул чын мәгънәсендә яхшы мисал әзләүчеләргә үрнәк булачак. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлләмнең тылсымлы сүзләре, һичкем тарафыннан кабатланмас тормыш үрнәге үзен сөяргә мәҗбүр итә. Ә инде сөю хисләре сөелгән кеше артыннан иярүгә китерә. Әйе, без аның кебек була алмасак та, "булдыра алмыйбыз" дигән булып, хәлдән килгәнчә мәрхәмәтлелек кылудан ерак торырга тиеш түгелбез.

*Мәхмүд хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН, Казан шәһәре казые, Шамил мәчете имам-хатыйбы*

# ХАЛКЫБЫЗ – ДОГАЛЫ ХАЛЫК

**Кол Шәриф мәчетендә татар коръәнхафизлары чиратлашып Коръән укый башладылар. Изге китап тәүлек дәвамында, көннәр, атналар, еллар дәвамында, Аллаһы боерса, бертуктаусыз укылачак. Бер төркем дин әһелләре, рәсми вәкилләр, башкалабызга килгән кунаклар, туристлар катнашында әлеге күркәм гамәлгә фатиха бирелде. Чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, "Казан Кремле" музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов һәм башкалар катнашты.**



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышын мәчеткә җыелган халыкны Мәүлид белән котлаудан башлады. "Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең туган көнендә Кол Шәрифтә Коръән укырга керешәбез. Изге китапны бертуктаусыз укырга өметләнәбез, ышанабыз. Барчабызга да мәгълүм, безнең бабаларыбыз Коръәнне зиратларга качып, өйләрендә яшертен генә укыган чорлар булган. Бүген Россиянең уртасында, Казан Кремле үзәгендә, Кол Шәриф мәчетендә Коръән укыла. Бу ни дигән сүз? Бу халкыбыз - догалы халык дигәнне аңлата. Без дога кылып яшәгән халык. Шушы мәчеттә Изге китапны уку, догалар әйтү илебезгә, җиребезгә, халкыбызга бәрәкәт, әҗер-саваплар китерсен иде!" - диде мөфти Камил хәзрәт.

Коръән-хәтем чыгу мөфтидән башланды. Аннары Казанның Салихҗан мәчете имам-хатыйбы Нурислам хәзрәт Ибраһимов дәвам итте. Изге китапта язылган сүзләрнең Раббыбыз сүзләре икәнен истә тотып, ихлас күңел белән Коръән уку - гыйбадәтнең бер төре. Аллаһы тәгаләнең безгә зур бүләге булган изге Коръәнне уку әҗер-саваплар китерә торган гамәл санала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм: "Коръәнне башыннан ахырына кадәр укып чыгу - Аллаһы тәгаләнең нуры белән нурлану ул", - дигән.

ТР МДНнең dumrt.ru сайтында һәм islam-today порталында Кол Шәриф мәчетеннән онлайн-трансляция алып барыла.







# Татарстан мөселманнары авыру ятимнәргә өй җылысы бүләк итте

**Теләче районының Иске Җөри авылында ятим һәм физик мөмкинлекләре чикле балалар өчен приют ачылды. Әлеге үзенчәлекле оешманы ачу тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, мөфти урынбасарлары Илдар хәзрәт Баязитов, Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Казан шәһәре мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Теләче районы имам-мөхтәсибе Исмагыйль хәзрәт Фәләхиев, район башлыгы Илдус Зарипов катнашты. Чарага төрле төбәкләрдән кунаклар килгән иде, шулай ук авыл халкы да әлеге күркәм вакыйганың шаһиты булды.**



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, чараны ачып, халыкны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм туган ай - Мәүлид ае белән тәбрикләде. Аннары әлеге приютны оештыручыларга - үзенең социаль эшләр буенча җаваплы урынбасары Илдар хәзрәт Баязитовка, приют директоры Мәликә ханым Гыйльметдиновага рәхмәт сүзләрен җиткерде. "Ятим балаларга ярдәм итү кебек социаль проектларны тормышка ашыру бүгенге көндә бик әһәмиятле. Моны мин республика мөселманнарының социаль хезмәт күрсәтү юнәлешендәге бер адымы дип саныйм. Мәүлид аен шушындый саваплы һәм күркәм гамәлләр кылып уздырырга язсын. Приютны булдыруга өлеш керткән һәм биредә эшләүче тәрбиячеләргә, Аллаһы тәгалә үзенең әҗер-савапларын мулдан бирер, иншә Аллаһ",- диде Татарстан мөфтие.

Приютка балалар 2014 елның 22 ноябрендә үк кабул ителә башлаган иде. Хәзерге көндә биредә авыр сынауларга дучар булган 3-18 яшьлек 10 нан артык бала җыелган. Алар төрле диагнозлы булудан тыш, әтиәниләреннән мәхрүм калганнар. "Биредә 20 баланы тәрбия кылу ниятләнелә. Аларның уку класслары, ял итә торган бүлмәләре булган мәдрәсәләре авыл мәчете каршында гына урнашкан, калган вакытларын уңайлы аерым бинада уздыралар. Приютны гамәлгә куючылар алдында бик зур бурыч тора. Бу балаларны тормышка яраклаштырып үстерергә, аларга өй җылысын бирергә, бөтен авырлыкларын җиңеләйтергә кирәк. Моның өчен приютта бар шартларны тудыру каралган. Тернәкләндерү, релакс, массаж бүлмәләре булдырылган", - диде мөфти урынбасары, Ярдәм мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов.



intertat.ru







# БИСМИЛЛӘСЕЗ БАШЛАНГАН ЭШНЕҢ АХЫРЫ ХӘЕРЛЕ БУЛЫРМЫ?

**Аллаһы Тәгалә безне Үзенең иге-чиге булмаган сыйхөрмәтләрендә, киң-киң нигъмәтләрендә яшәтә. Аның безгә биргәнен санарга уйласаң - саның, сөйләргә алынсаң - сүзең җитмәс. Нигъмәтләрнең күз белән күреп, тотып була торганы, күренмәсә дә, күңел илә тоеп була торганнары бар. Сезләргә Раббыбызның олуг бер бүләге - "бисмиллә" турында сөйлисем килә. Әлеге изге сүз безнең халыкка аеруча якын, кадерле сыман тоела. Чөнки динсезлек чорларында әби-бабаларыбызны намаздан, рузадан гына түгел, хәтта бисмилләдән дә мәхрүм итәргә тырышканнар. Әмма күңелендә иманын саклаган әби-бабаларыбыз бисмилләсез бер эшкә дә тотынмаганнар. Раббым алардан разый булсын.**


NTRTV.RU

Сөекле Пәйгамбәребез: "Һәрбер мөһим эш ***"Бисмилләһ"сез башланса, ул эш өзелер",*** - диде.

Әлхәмдүлилләһ, динсезлекнең салкын кышлары китеп, иман язларының җылы кояш нурлары безгә дә төшә башлады кебек. Бүген бисмиллә әйтеп эш башлаучыны дошман күрмиләр. Шөкер, түрәләребез дә гаетләрдә сүзләрен бисмилләдән башлыйлар. Сайлау алдыннан Жириновский да бисмилләсен әйтте әле. Әлхәмдүлилләһ, бисмилләне әйтәбез, бисмилләгә кайтабыз, әмма без аның асыл мәгънәсен аңлап бетерәбез микән? Бөек сүзнең чын кыйммәтен, кадерен беләбез микән? Әйдәгез, сандыкны бергәләп ачыйк, анда булган энҗе-мәрҗәннәргә күз салыйк.

**"Бисми-ЛЛәһи-Р-Рахмәни-Р-Рахим - әлеге бөек сүз өч өлештән тора:**

**1."Бисми-ЛЛәһ" - "Аллаһ исеме белән".** "Аллаһ" - барча галәмнәрне юктан бар кылып, кайгыртып, тәрбия кылып торучы Раббыбызның иң бөек исеме (гарәпчә "Әллааһу"). Билгеле булганча, үз исемнәребезне һәрвакыт баш хәрефтән язабыз, Аллаһ исемен дә баш хәрефтән язу зарур. Аллаһ бар галәмнәр белән идарә итә, Аның әмере белән җир һәм күкләр, кояш, ай, йолдызлар яши. Җир әйләнә, көн белән төн алышына, яңгырлар ява, диңгез-елгалар ага. Раббыбызның әмере илә берәүләр килә, икенчеләр китә. Җир һәм күктә булган бар затлар - Аның мәхлуклары (мәхлук - халык кылынган, создание дигәнне аңлата), барысы да Аның каршында бәндәдер (фарсыдан - кол), Аңа гына кол булып, Аңа гына гыйбадәт кылырга тиешләр. Аллаһ тумады һәм тудырмады, Аның хатыны һәм баласы булмады. Ул Бердәнбер, бер ялгызы, юктыр Аның һич тиңдәше.

Күп кенә татар гаиләләрендә таралганча, Аллаһы тәгаләгә "Алла бабай" дип әйтү, зур гөнаһ булып тора. Беренчедән, бабай - ир заты, ә Аллаһ ир түгел, хатын түгел. Кайбер диннәрдәге кебек Аллаһыны ир затыннан санау исламда зур гөнаһ санала. Икенчедән, бабай карт була, Аллаһ исә Мәңгелек, яшь яки карт булмый. Шулай ук, Раббыбызның исеме - Аллаһ, Алла түгел, анысы да бик мөһим. "Алла сакласын", диләр, машина тәрәзәләренә язалар. Алла дигәч, күз алдына Пугачева килә, ә Раббыбыз Алла түгел, Аның исеме Аллаһ. Шуңа күрә "БисмиЛЛәһи" дип, дөрес итеп әйтергә кирәк. "Бисмиллә-Иррахмәниррахим" дип "һ" хәрефен калдырып әйтү, Аллаһ исемен бозып әйтү була. Элек хәлфәләр шәкертләрне өйрәткәндә: "Бисмиләһи" дип укыганда, "һ" хәрефен әйткәндә кендекләрегез селкенсен", - дия торган булганнар.

Кемдер: "Ә ник алайса мәкаләнең исемендә "бисмилл"нең "һ" хәрефе юк?" - дип әйтер. Мин "бисмиллә" дип язганда да, моны бөек сүзнең үзе түгел, аның аталышы дип кабул итегез. Чөнки галимнәрнең гарәпчә хезмәтләрендә дә әлеге сүзнең исеме "бәсмәлә" дип әйтелә.

Кайбер кешеләр: "Бисмиллаһи-ррахмани" дип "л" һәм "м" хәрефләрен каты итеп әйтәләр, бу фарсыдан кереп калган гадәт, гарәп теленДә дөрес түгел. "БисмиллӘәһи" дип "л" хәрефен нечкә һәм сузып, "...-рРахмӘәни" дип "м" хәрефен дә нечкәртеп, бераз сузып укырга кирәк.

Шулай ук бисмилләнең беренче өлеше - "Бисмилләһи" калган өлешеннән аерым, мөстәкыйль рәвештә дә килергә мөмкин. Мисал өчен, эш башлар алдыннан тулысынча "Бисми-ЛЛәһи-РРахмәни-РРахим" дип әйтмичә, "Бисмилләһ" дип кенә әйтү дә җитә. Ә кайвакыт, Пәйгамбәребез кыскартып әйтү сәбәпле, шулай хәерлерәк тә була.

**2."Әр-Рахмәән" - Рәхимле (Всемилостивый).** Раббыбызның "Әр-Рахмән" һәм "әр-Рахим" исемнәре икесе дә Аның бөек рәхмәтенә кайта, рәхимле булуын аңлата. Аллаһ Үзенең Рәхимле булуын ни өчен ике исем белән белдерткән соң? Моның хикмәте бар. Аллаһының бәндәләренә карата рәхмәте ике төрле була икән. "Әр-Рахмән" дигән бөек исеме Аның бу дөньяда бар бәндәләренә карата да рәхимле булуын аңлата. Игътибар итегез, дөньялыкта Раббыбызның ризыгы бөтен кешегә дә килә, кояш нурлары барысына да ирешә. Иманлы да, кәфер дә, гадел дә, залим дә Аллаһының күпме нигъмәтендә яшиләр. Кайберәүләрнең гомере буена бер мәртәбә "Аллаһка шөкер" дигәне юк, ә Аллаһ аны яшәтә, ашата, кайгырта... Бүген дә күпме кеше "Аллаһ юк" дип көферлектә яшәп, Аның ризыгын ашый, Аның суын эчә, Аның һавасын сулый... Ул биргән күзләр белән күрә, аяклар белән йөри, куллар белән хезмәт итә. Раббысының меңләгән нигъмәтен күрми, бер авырлык бирсә: "Ни сәбәпле, нигә миңа?!" - дип зар кылырга тотына.

Кайвакыт Аллаһ хикмәте белән имансыз кешегә дөньялыкта күбрәк тә бирергә мөмкин, чөнки аны мәңгелек йортта газаптан башкасы көтми. Пәйгамбәребез: ***"Дөнья - иманлының төрмәсе, имансызның җәннәте"***, - диде (Имам Мөслим җыентыгыннан).

**3."Әр-Рахим" - Рәхимле (Милостивый).** Аллаһының әлеге исеме Аның ахирәттә иман ияләренә генә рәхимле булуын аңлата. Әгәр дөньяда бар мәхлуклары Раббыбызның рәхмәтендә яшәсәләр, ахирәттә имансызлар Аның рәхмәтен, кызгануын күрмәсләр. Аллаһыдан газапны киметүне кат-кат сорап ялварырлар, үкенүдән бармакларын чәйнәрләр, әмма аларга Раббының рәхмәте иңмәс. Ләкин Аллаһ һичкемгә газапны тиешеннән артыгын бирмәс.

Еш кына кешеләрдән: "Ни өчен Аллаһ залимнәрне тотмый? Ник Ул аларны җир өстендә яшәтә?" - дигән сораулар ишетергә туры килә. Аллаһ кемне кайчан тотасын Үзе белә, вакыты җиткәч, Үзе хәл итә.

Аллаһы тәгалә: "**Кеше ашыгучан булып яралтылды. Мин сезгә Үз аятьләремне күрсәтермен, сез Мине ашыктырмагыз**", - диде ***("Пәйгамбәрләр", 37 нче аять)***.

Дөньялыкта Аның рәхмәтендә, нигъмәтендә барысы да яшәвен дәвам итә, ахирәттә имансызларны үкенечле газап көтә. Әмма, бу хакыйкатьне аңлау өчен, Аллаһыга ышану гына җитми, үлгәннән соң терелүгә, Раббыбыз каршына басасы көнгә инану кирәк. Гомумән, ахирәткә, Кыямәт көненә иман китермәгән кешегә тормышта күп нәрсәләрне аңлау мөмкин түгел.

Шулай итеп, эшебезне Рәхимле Аллаһ исеме белән башлыйбыз, Аның ярдәменә, рәхмәтенә өметләнәбез.

Бисмилләнең дөрес укылышы: **"Бисми-лЛәәһи-р-Рахмәәни-р-Рахиим"** була.

### Иң хәерле өч исем

Шулай итеп, бисмиллә үз эченә Аллаһының өч бөек исемен алды. Балага әлеге исемнәрнең алдына "Габд..."- кол дип өстәп кушылган исемнәр динебездә иң изге исемнәр санала. Габдуллаһ - Аллаһ колы, Габдрахман - "әр-Рахмән" колы, Габдеррахим - "әр-Рәхим" колы.

Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә "бисмиЛЛәһ"не төрле җирләрдә әйтүе хәбәр ителә. Урынына, халәтенә карап, аның үз максаты, үз фазыйләте булырга мөмкин. Шундый урын һәм халәтләрнең берничәсенә тукталып китәсем килә:

● **"Бисмилләһ" - таһарәт алганда.**

Әбү Һурайра тапшырган хәдистә, пәйгамбәребез: ***"таһарәте булмаган кешенең намазы юк, Аллаһының исемен зикер итмәүченең тәһарәте юк"***, - диде (Әхмәд, Әбү Дауд, Ибне Мәҗәһ).

Әлеге очракта бисмилләне әйтү кылган эшнең камиллеген, дөреслеген тәэмин итә. Бу хәдискә нигезләнеп, кайбер галимнәр бисмилләсез таһарәте алу дөрес булмас дип аңлаттылар. Кайберләре таһарәтнең башында оныткан кеше, исенә төшкәч тә әйтсен, диделәр. Әбү Хәнифә мәзһәбендә исә бисмилләне әйтү саваплы, әмма мәҗбүри булмаган сөннәт эш санала.

● **"Бисмилләһ" - мал суйганда.**

Аллаһы тәгалә хәләл кылган хайваннарны мөселман кешесе Аллаһ исеме белән суярга тиеш. Бисмилләсез чалынган мал хәләл саналмый.

Әнәс ибне Мәлик сөйләвенчә: ***"Пәйгамбәребез корбан малын Аллаһының исемен искә алып - Бисмилләһи, - дип һәм Аллаһыны бөекләп - Әллаһү әкбәр, - дип чалды"*** (Бохари һәм Мөслим).

Кайбер кешеләргә ашка барып: "Ашыгыз хәләл микән?" - дип сорасаң, алар гаҗәпләнеп: "Әйе, ул тавык итеннән бит", - диләр. Кошчылык фабрикаларында бисмилләсез суелган тавык итләре динебездә хәрам санала. Ләкин мөселман кешесе мал суйганда бисмилләсен әйтергә онытса, ит хәрам булмас.

● **"Бисмилләһ" - ризык алдыннан.**

Гомәр ибне Әбү Сәләмә кечкенә чагында табын янына килеп, кулын ризыкка суза, Пәйгамбәребез аңа: ***"Әй, егет, Аллаһының исемен әйт, уң кулың белән аша, үз алдыңнан аша"***, - дип әйтә (Бохари һәм Мөслим).

Әгәр бер кеше ашар алдыннан бисмилләсен онытса, исенә төшкәч тә әйтергә тиеш. Пәйгамбәребез: "Әгәр берегез ризык ашаса: "БисмиЛЛәһи" дисен, ә онытса: ***"БисмилЛәһи фи әүвәлиһи вә әәхыйриһи", дисен"***, - диде (Тирмизи, Ибне Мәҗәһ). Тәрҗемәсе: "Башында да, ахырында да Аллаһ исеме белән".

Ризыкка бәракәт китерә. Кечкенә вакытта, әбиләр: ***"Балам, бисмилләңне әйтеп аша, тамагың туяр"***, - дип әйтәләр иде. Еш кына кешенең ризык, малдан канәгатьлеге аның аз булуыннан түгел, бәракәтсез булуыннан килә. Бервакыт, Пәйгамбәребезнең алты сахабәсе белән табын артында утырганда, бер бәдәви килеп, булган ризыкны ике кабуда ашап бетерә. Пәйгамбәребез: ***"Әгәр ул Аллаһ исемен әйткән булса, ризык сезгә дә җитәр иде"***, - дип әйтә (Әхмәд, Тирмизи, Ибне Мәҗәһ).

● **Өйгә кергәндә һәм чыкканда.**

Кешенең өе аның үзе һәм гаиләсе яши торган урыны. Әлбәттә, мөселман өен җен һәм шайтаннардан саклар өчен тырышлык куярга тиеш. Өйгә кергәндә Аллаһ исемен искә алу, безгә ияреп керергә теләгән шайтаннарны урамда калдыра. Кирәкмәс кешеләр өебезгә килеп кермәсеннәр дип ишекне бикләсәк, шайтан-

*(Ахыры 11 нче биттә.)*

# ТӘКЪДИРГӘ ЫШАНУ

**Тәкъдиргә ышану - ул яхшының да, яманның да Аллаһы тәгалә боеруы белән һәм Аның мәңгелек гыйлеменә туры килерлек рәвештә барлыкка килүенә инану.**



Ислам буенча кеше үзенең кылганнары өчен җавап тотамы, дигән сорау туарга мөмкин. Әлбәттә, җавап тота. Җаваплылык без һәркөнне кыла торган ниятле гамәлләргә бәйле. Бу гамәлләр безнең гәүдәләребез тарафыннан эшләнә яки уй-фикерләребезгә бәйле. Шулай да аларны Аллаһы тәгалә алдан ук билгеләп куйган.

Безнең тормышыбыз бик күп уй-ниятләр һәм карарлардан тора. Билгеле шартларда нинди карар кабул итәчәгебезне Аллаһының алдан белүе безне шул карарлар өчен җаваплылыктан азат итми, ягъни без уйланырга, сайларга һәм дөрес юлны таба белергә тиеш. Без тәкъдирдә ниләр язылганын белмибез. Раббыбыз безнең ниятләребезне барлыкка китерә, ләкин шул ниятләрне гамәлгә ашыручы без. Ниндидер бер нәрсәне ниятләгәндә без башка нәрсәгә дә ният кылу мөмкинлеге барлыгын сизәбез, ләкин берәү дә безне сайларга мәҗбүр итми.

Шуны да истә тотыйк, Аллаһы тәгалә безгә берниндидә гамәлләр кылдырмыйча, башта ук тәмуг уты эчендә барлыкка китерә алыр иде. Тик бу җәза түгел, газап булыр иде. Үзенең мәрхәмәт-шәфкате белән Ул алай эшләмәгән, безне шушы дөньяда барлыкка китергән һәм безгә тиешле кагыйдәләр җиткергән. Фани дөньяда Аллаһының кушканнарын белә торып үтәмәгән өчен бакый дөньядагы газапларыбыз җәза дип атала.

"Бер кешене Аллаһы тәгалә мөселман итеп ярата да аны бүләкли, ә башка берәүне индуист итеп ярата һәм җәзалый: бу гадел күренешме инде?" - дип сорарга мөмкин. Аллаһы берни дә эшләргә тиеш түгел, безнең гамәлләребез Аңа берничек тәэсир итми. Яхшы гамәлләр җәннәткә керү хокукы бирми, анда керү Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәт-шәфкатенә бәйле. Кайберәүләргә Аллаһы яхшы эшләр башкаруны җиңеләйткән, ә кемнәргәдер - юк. Кайберәүләргә Ул изгелекләр кылуда кыенлыкларны уза белү мөмкинлеге биргән, ә кемнәргәдер - юк. Аллаһы тәгалә кешеләрнең бер өлешен - җәннәт өчен, икенче бер өлешен тәмуг өчен яралткан. Бу гаделсезлек түгел, чөнки Аллаһының яратучысы да, Ул җавап бирергә тиешле хөкемдары да юк. Ул барлыкка китерגәннәр бары тик Аныкы гына һәм Раббыбыз алар белән Үзе теләгәнен эшли ала. Аллаһы тәгаләне рәхимсез дип әйтергә ярамый, чөнки Аны кешелек критерийлары (һәм башкалары) белән бәяләп булмый.

Аллаһы тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Аллаһы, Аңа мактау һәм данлау булсын, үзенең эшләгән эшләреннән соралмас, чөнки Ул Бөек Хуҗа, әмма Ул барлыкка китергән затлар эшләгән эшләреннән соралырлар" ("Әл-Әнбия" сүрәсе, 23 нче аять).

Аллаһы тәгаләнең гамәлләре хакында хөкем йөртү Аңа буйсынмау була.

Имам әт-Тәһави болай дигән: "Тәкъдир - Аллаһы тәгалә барлыкка китергән сер ул. Раббыбызга якын булган фәрештәләргә дә, Ул безгә җибәргән пәйгамбәрләргә дә бу хакта белемнәр бирелмәгән. Тәкъдирнең асылы турында күп һәм тирәнтен уйлану ялгыш юлга, югалтуларга һәм гөнаһларга этәрә. Шуңа күрә кирәкмәгән уйлардан, ялгыш фикерләрдән саклагыз. Аллаһы тәгалә кешелектән тәкъдир турындагы белемнәрне яшергән һәм аларны эзләүне тыйган".

***"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән***

# БИСМИЛЛӘСЕЗ БАШЛАНГАН ЭШНЕҢ АХЫРЫ ХӘЕРЛЕ БУЛЫРМЫ?

***(Ахыры. Башы 10 нче биттә.)***

нарга тимер ишек киртә түгел. Шуңа күрә кечкә ишекләрне бикләгәндә бисмилләне дә әйтергә онытмыйк.

Пәйгамбәребез әйтте: ***"Әгәр бер кеше өенә кергәндә һәм ашаганда Аллаһ исемен искә алса, шайтан: "Сезгә монда куну да, кичке аш та юк", - дияр. Әгәр өенә кергәндә Аллаһ исемен искә алмаса, шайтан: "Сезгә кунарга урын бар", - дияр. Аллаһыны искә алмый ашаса: "Сезгә куну урыны да, ашау да булды"***, - дияр" (Мөслим).

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез: ***"Кичкә ирешсәгез, сабыйларыгызны өйләрегезгә кертегез, ул вакыт шайтаннар тарала. Төн килеп җитсә, ишекләрне бикләгез һәм Аллаһының исемен искә алыгыз. Шайтан бикле ишеккә кермәс. Су савытларын бәйләп куегыз, Аллаһ исемен искә алыгыз. Савыт-сабаларның өстен каплагыз, Аллаһ исемен искә алыгыз"***, - диде (Бохари һәм Мөслим).

Өйдән чыкканда да иман иясе гаиләсен, өен, байлыгын, үткәрәсе көнен Аллаһка тапшырса, нәтиҗәсе булмый калмас. Пәйгамбәребез: "Кем өеннән чыкканда: "Бисмилләһи, тәвәккәлтү галәллааһи, ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһи - Аллаһ исеме белән, Аллаһка тапшырдым, Аллаһтан башка көч тә, куәт тә юк", - дисә, аңа: "Сиңа шушы җитте, син сакландың, - диелер һәм аннан шайтан китәр" - диде (Тирмизи, Әбү Дауд).

● **Йокларга ятканда**.

Пәйгамбәребез: ***"Әгәр берегез йокларга ятса, ятак өстен каксын һәм Аллаһ исемен искә алсын. Ул үзеннән соң ятакта ниләр булганын белми"***, - диде (Бохари һәм Мөслим).

Элгәре заманнарда кешеләр җиңелчә чатырларда, гади өйләрдә яшәгәннәр. Көн буена өй эченә әллә нинди хәшәрәтләр, бөҗәкләр, хәтта чаяннар керергә мөмкин. Гадәттә, кеше йоклаган урында аның тән, тир исе калып, ис шул бөҗәкләрне җәлеп итәргә мөмкин. Шуңа күрә, сөекле Пәйгамбәребез йоклар алдыннан урын өстен җиңелчә кагып алырга чакырды. Бүген яшәгән йортларыбызда әллә ни бөҗәкләр юктыр, ләкин, кешенең тире катламы алышынып, искесе коелу сәбәпле, ул урында күзгә күренми торганнары бар. Шуңа күрә бүгенге көндә дә Пәйгамбәр өйрәтеп калдырган эшнең хикмәте актуаль.

● **Бәдрәфкә кергәндә.**

Шайтаннар нәҗес-тизәк ашыйлар, шуңа күрә йомыш үти торган урыннар аларның җыелышу урыннары булып тора. Аларның зыяннары тимәсен өчен Пәйгамбәр кергәндә укый торган махсус догасын дә өйрәтеп калдырды. Моннан тыш кеше йомышын үтәгәндә оят җирләрен ачарга мәҗбүр була. Әгәр адәмнәрнең күзеннән дивар белән яшеренсәк, дивар аша үтүче шайтаннардан ничек яшеренергә? Пәйгамбәребез: ***"Кешенең бәдрәфкә кергәндә "Бисмилләһ" дип әйтүе җеннәрнең күзләре белән кешеләрнең гаурәтләре арасында пәрдә булып торыр"***, - диде (Тирмизи һәм Ибне Мәҗәһ риваятьләре).

Димәк, бу урында бисмилләбез оят җирләребезне җеннәрдән яшерә.

● **Атка-дөягә утырганда.**

Пәйгамбәребез: ***"Һәр дөянең сыртында шайтан утыра, шуңа күрә утырыр алдыннан Аллаһ исемен искә алыгыз"***, - диде (Әхмәд, Дәрими, Табәрани).

Атка, дөягә, машинага утырганда бисмилләне әйтеп утырсак, без утырасы урынга утырып өлгергән шайтан шундук урынны бушата.

● **Бисмилләнең файдасы - китеп баручы буынга да, киләсе буынга да.**

Вафат булган кардәшләргә: Ибне Гомәр тапшыра: "Пәйгамбәр мәетне кабергә төшергәндә: "Бисмилләәһи вә галәә милләти расүүлиЛЛәһи", - дип әйтә иде (Тирмизи, Имам Әхмәд). Тәрҗемәсе: ***"Аллаһ исеме белән Аллаһ Илчесенең дине буенча".***

Динебез хәләл җефетләргә җенси мөнәсәбәт алдыннан да Аллаһ исемен искә алырга өйрәтә. Моның ике хикмәтен әйтергә була. Беренчесе: чит кеше белән зина кылу никадәр гөнаһлы эш саналса, үзеңнең хәләлең белән якынлык кылу шулкадәр саваплы була. Икенчесе: дошманыбыз шайтан ир белән хатын-кыз арасына кереп, аларның араларын бозарга тырыша. Шайтан җенси мөнәсәбәттән дә ерак йөрми. Ибне Габбәс тапшыра, Пәйгамбәребез: ***"Әгәр берегез хәләл җефете белән якынлык кылырга теләсә: "Бисмилләһи. Йә, Аллаһ, безне һәм безгә ризык итәсе балабызны шайтаннан сакла", - дисә, шуннан хатын-кыз балага узса, аңа шайтан зарар салмас"***, - диде (Бохари һәм Мөслим).

● **Хайван абынганда.**

Пәйгамбәребез Әбү Тәмимәне артына утыртып барганда, ишәге абына. Әбү Тәмимә: ***"Шайтан һәлак булсын", - дип әйтә. Пәйгамбәр аңа: "Шайтан һәлак булсын", - димә. Син алай дисәң, ул бөекләнеп китә һәм: "Мин аны көчем белән егып төшердем", - дип әйтә. Әгәр шулвакыт: "Бисмилләһ", - дисәң, ул кечерәер һәм чебен кебек калыр"***, - дип әйтә (Әхмәд, Әбү Дауд).

Берәр эшебез барып чыкмаса, яки аяк бармагын караватбашына бәрсәк, шундук шайтанны сүгәргә тотынабыз. Ләкин бу аны сөендерә генә, шайтанны түгел, Аллаһыны искә алыйк.

Моннан тыш, Пәйгамбәрнең күп кенә урыннарда Аллаһ исемен искә алу мисаллары килә: мәчеткә кергәндә һәм чыкканда, малны чалганда, аучы мылтыгыннан атканда, сугыш кырында, башка авырлык төшкәндә, авырганда, өшкергәндә...

Һәр изге, җаваплы, авыр эшләребез Аның исеме белән башланса, ярдәменнән ташламас, хәерле нәтиҗә, бәракәтен бирер, иншә Аллаһ. Йә, Раббым, Сине онытмаган, бисмилләсен калдырмаган, ахыр сулышына кадәр иман белән яшәгән, иман белән киткән әби-бабаларыбыздан, әти-әниләребездән разый бул. Безгә дә Синең исемеңне онытмыйча яшәргә насыйп әйлә.

***Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,***
***Түбән Кама шәһәре һәм районы мөхтәсибе***

# МУЛЬТФИЛЬМ: яхшымы, яманмы?

**Мультфильм... Аны карамаган, яратмаган бала бар микән? Шаян, шук җанварлар, тере машиналар дисеңме, компьютер дөньясында гына яшәгән геройлармы - барысы да баланы үзенә җәлеп итеп тора. Әллә нинди ысуллар, геройлар уйлап табып кызыктыра белә бүген мультфильм ясаучылар. Бигрәк тә Америка абзыйлары бу яктан нык тырыша.**

### Хатын-кыз образы

Көнбатыш мультфильмнарындагы хатын-кыз образына игътибар иткәнегез бармы? Аларның һәрберсендә хатын-кыз сылу гәүдәле, зур күзле, калын иренле, мул күкрәкле итеп сурәтләнә. "Плейбой" журналы өчен менә дигән героиня! Ә безнең балаларыбызга хатын-кызны мондый итеп күрсәтү ник кирәк?

Ничә еллар телевизор экраннарыннан төшмәгән, сабыйларыбыз гына түгел, ә үзебез, ата-аналар да үз иткән "Алладин", "Шрек" мультфильмнарын гына мисал итеп алыйк. Беренче карашка, алар яхшылыкка өйрәтә кебек - яман көчләр, тискәре геройлар белән көрәшәләр бит. Ләкин игътибарлырак булыйк. Совет мультфильмнарындагы хатын-кыз образын хәтерлисезме? Аларның барысында да кызлар озын сарафаннан, үзләре самими, тыйнак, оялчан итеп тасвирлана. Нәкъ мөселман кызы инде! Ә алда атап үтелгән мультфильмнардагы Жасмин белән Фиона образлары балаларга түгел, ә аларның аталарын кызыктырыр өчен тудырылган диярсең! Әчке күлмәк кигән, кендек күрсәткән, ирләр белән сугышырга да көч тапкан хатын-кыз балага нинди үрнәк күрсәтә?

### Ир һәм хатын-кыз арасындагы аерма

Еш кына Америка мультикларында төп героиня хатын-кызларга хас сыйфатларны читкә куеп, супермен буларак тасвирлана башлый: зур бер армиягә каршы көрәшә һәм, әлбәттә, җиңү яулый. Робот һәм мумияләр турындагы мультикларны әйтсәң дә юк! Хатын-кыз кыяфәтендәге героиня җәһәннәмнән чыккан, зур көчкә ия булган Иблис рәвешендә күрсәтелә. Ә бит без балаларыбызга кечкенәдән үк ирнең - көчле зат, ә хатын-кызның - көчсез зат булуын төшендерергә тиеш. Көне-төне мондый мультиклар карап "җенләнгән" балалар ир-ат һәм хатын-кыз арасында булган аерманы күрми башларга да мөмкин. Киләчәктә бу нәрсәгә илтер? Сексуаль ориентация югалткан яшьләр санын арттырмас дип кем әйтә ала? Җәмгыятебездәге "унисекс" дип аталучы яшьләр стиле, бәлки, шул мультипликацион унисексның дәвамыдыр?

### Игътибарны юнәлтү серләре

Өлкәннәр сизмәгәндә генә, безнең балаларыбыз әлеге чит илнең бозык мультфильмнары колына әйләнә бара. Ничек эшләнә соң бу?

Беренчедән - төс. Төп геройлар, гадәттә, бик ачык, кычкырып тора торган, ә кайвакыт хәтта "агулы" төсләргә буяп бирелә. Ә балаларга гадәти булмаган, төсле, башкалардан аерылып торган нәрсәләргә игътибар итү хас. Шуңа да күп балалар телевизорда реклама башланса, бөтен эшләрен ташлап, гипнозланган төсле, экранга текәлеп утыра. Хәтта минем 5 айлык балам да моңа алдана.

Икенчесе - йөз. Атаклы "Дисней" мультикларындагы героиняларга игътибар белән карагыз әле. Аларның барысында да бер үк йөз, бары күз, чәч төсе генә үзгә. Әлеге кызны чынбарлыкта күз алдына китерсәң, ничектер куркыныч булып китә, чөнки тормышта мондый йөзле кеше гүзәл түгел, ямьсез булыр иде. Ләкин кызлар әлеге мультфильмнарны шулкадәр еш карый, хәтта алар героиняның ямьсезлеген күрми үк башлый, киресенчә, ул аларның кумирына әйләнә - кызлар аңа охшарга тырыша. Шулай булмыйча ни! Бу героиняга ак атка атланган принцлар гашыйк була бит! Ә малайлар, үсә төшкәч, шушындый "гүзәл" кызларны эзли башлый. Менә шулай итеп бала аңында ямьсезлекне гүзәллек, ә гүзәллекне ямьсезлек белән бутау барлыкка килә.

### Чит илнекеме, үзебезнекеме?

Чит ил мультфильмнарының бирелешен генә алыйк. Шау-шулы, акыру-чинау, көчле музыка тавышы белән үрелеп барыла. Игътибар белән карамасаң, бүреләрен эттән, тычканны песидән аерып булмый. Ә үзебезнең ил аниматорлары мультик геройларын тормыштагыча күрсәтергә тырышалар. Папанов сөйләткән бүрене, Румянцеваның куянын карап үстек без. Ул мультикны ничек көтеп алганым әле дә хәтердә. Хәзер ул да балаларга күрсәтергә тыелганнар исемлегендә. Ә бит бала бүренең тәмәке тартуының зыянын күрә: бүре аңын югалтып егыла... Чит ил мультфильмнарында хулиганлык күренмиме, үзеңнән көчсезләрне рәнҗетү юкмы? "Том и Джерри" гына да ни тора! Ул тычканның песигә күрсәткәннәре... Чынбарлык тормышта бу мәче беренче көнне үк җан тәслим кылган булыр иде инде. Һәр өйдә песи барлыгын исәпкә алсаң, бала песи интектерүне үз "һөнәре"нә әйләндермәсме?

### Баланың үз-үзен тотышына мультфильмның тәэсире

Баланың үз-үзен тотышына аның нинди мультфильм каравы, кайсы геройларны үз итүе зур йогынты ясый. Чөнки мультгеройлар аның өчен чынбарлыктагы кеше образы кебек. Шуңа анда тирә-як җәмгыять турында да ялган фикер урнашырга мөмкин. Мультфильмдагы тискәре образны үз итмәс дип, кем әйтә ала? Күп очракта әлеге тискәре герой зур көчкә ия, сүз артыннан кесәгә керми торган итеп тасвирлана бит. Кайсы малайның көчле буласы килмәсен?

Кечкенә кызчыклар турында әйтеп тору кирәк микән? Кызларыбыз үзләренең яраткан героиняларын, аларның үзүзләрен тотышын кабатлый, алар кебек кыланып сөйләшә. Ә бит күп көнбатыш мультфильмнарында хатын-кызларга хас традицион сыйфатлар көлке рәвешендә күрсәтелә. Оялчанлык, гадилек, самимилек, ана булу - болар барысы да әлеге героинялар өчен ят нәрсә. Кыска итәк, "шәп прическа", озын үкчәле туфли, матур кием - яхшы, "круто", ә күзлек кию, бизәнмәү, китап уку - начар сыйфат, ул "ботаник"ларга гына хас. 10 яшьлек сеңлемнән алган җавап бу. Ә китап укып, белемле булуның ни начарлыгы бар соң? Әлеге мультфильмнар баланың тормышына шулкадәр үтеп керә, хәтта бала ата-ана белән талашуга кадәр барып җитә. "Миңа "понилы дәфтәр алыгыз", "Бетмэнлы сумка алмасагыз, мәктәпкә бармыйм" кебек таләпләрне дә еш ишетә хәзер ата-ана. Чит ил мультфильмнарына күзәтү ясаганнан соң, аларның төп максатларын аңладым: алар балаларыбызның аңнарын томалау, адаштыру өчен ясала икән бит.

Әлбәттә, балаларны мультфильм караудан мәхрүм итеп булмый. Ләкин ата-аналар яхшы белә: һәр ялтыраган әйбер алтын түгел. Никадәр матур һәм якты булса да, без бит балаларны утка якын китермибез, аны саклыйбыз. Ә ни өчен соң аларның әле ныгымаган психикасы турында кайгыртмыйбыз?..

*Мәрьям АБДУЛЛИНА, КФУ студенты*

# Зәмһәрир суыклар да мәчеткә юлларын кисмәде

**Балалар өчен мөселман лагерьлары оештыруда Казанның Гаилә мәчете коллективы инде шактый тәҗрибә туплады, чөнки ачылышыннан бирле бер генә сезонда да балаларны җыймый калганнары юк. Аллаһы ризалыгы өчен эшлим, дип шундук мөгаллим-шәкертләре килеп җитә, иганәчеләре бушлай ризыгын китереп бирә. Менә быелгы кышкы каникулларда да лагерьга 80 баланы кабул иттеләр.**

- Узган сезоннардан алган тәҗрибәбез эш алымында кайбер үзгәрешләр кертү кирәклекне күрсәтте. Балаларның тәртибенә, мәчет әдәбен үтәүләренә игътибарны арттырдык. Ә укыту-тәрбия эшчәнлеген, гадәттәгечә, мәчет имамнары, мәчет каршындагы курсларда укытучы мөгаллимнәр, Россия ислам институты шәкертләре һәм мәхәллә тормышында актив катнашучы ханымнар-туташлар башкарды, - ди Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм Хәйруллин.

Дөресен генә әйткәндә, лагерьның беренче көнненнән үк парта артына кереп утырган балаларыбызны күргәч, озакка барыр микән, дип уйлап куйган идек. Каникуллар бит, сыйныф бүлмәсендә түгел, өйдә дә утырып торасы килми торган чак. Ике-өч көн эчендә Коръәннән озын-озын сүрәләр ятлаулары турында ишеткәч тә ышанырга да-ышанмаска да белмәдек.



- Алай гынамы, зәмһәрир суыклар да мәчеткә юлларын кисмәде, - ди лагерь директоры Лилия Җиһаншина. - Бу юлы без аларга әби-бабайларыбыздан килгән тәрбияне - татар мөселман гореф-гадәтләрен сеңдерергә тырыштык, чөнки үзегез беләсез, андый тәрбия бик аз гаиләләрдә генә сакланып калган. Элек аны искелек калдыгы санасалар, хәзер бик тә заманча икәнлеген инде күпләр таныды. Кичә генә сыра эчү, тәмәке тарту модада булса, бүген сәламәт яшәү рәвеше, спорт белән шөгыльләнү, рухи яктан, шәхес буларак үсү хуплана. Ә болар барысы да исламда һәм безнең милли тәрбиябездә бар. Балаларга ике фәнне - Коръән һәм ислам нигезләрен укыттык. Торгач, йокларга ятар алдыннан, ашар алдыннан, ашагач нинди догалар укырга - шуларны өйрәттек.

Лагерьның ябылу тантанасында балалар алган белемнәрен ата-аналарга һәм килгән кунакларга да күрсәттеләр. "Безнең бабайларыбызның зирәклегенә хәйраннар калам. Исламны кабул итеп, алар ислам нигезендә төрки-татар цивилизациясе төзегәннәр. Динебез безгә мөстәкыйль милләт булып сакланып калырга да ярдәм итәр, иншә Аллаһ. Татарстан мәчетләрендә менә шулай татарча сөйләшеп торырлар..." - дип үз фикерләрен җиткерде килгән кунакларның берсе - мәхәлләдәшебез язучы Ркаил Зәйдулла.

Соңыннан Рөстәм хәзрәт балаларга Мәүлид күчтәнәчләре өләште.

*Мәрьямбану ХАФИЗ*

# ИР-АТ ВӘ ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ГАИЛӘДӘГЕ УРЫННАРЫ

**"Әгәр мин берәүгә башка берәү алдында сәҗдә кыл дип әмер иткән булсам, хатын-кызга ире алдында сәҗдә кылырга дияр идем", - бу хәдис-шәриф хәзрәти әт-Тирмизи җыентыгында китерелгән. Хатын-кыз иренә итагатьле булса, Аллаһы тәгалә ул хатыннан разый, канәгать булыр. Бу хакта Рәсүлебез салләллаһу галәйһи үә сәлләм: "Кайсы гына хатын булмасын, әгәр ире аннан разый булса, ул җәннәткә керер", - дигән. Әлбәттә, мөэминә, мөслимә хатын-кыз мөэмин иргә генә буйсыныр, башка ир турында сүз бармый. Инде хатынның ире шәригать таләпләренә туры килмәгән яки гайре мөселман кеше булса, бу очракта гамәл-гыйбадәт үтәр өчен иреннән рөхсәт сорап тормаса да, иренең алдында башка бурычлары булуын онытмас.**



Сөләйман галәйһиссәлам: "Гакыллы хатын иренең йортын төзек, сәламәт тотар, бозык күңелле хатын исә ул йортны ишәр", - дигән.

Хәзрәти Кәгъб әл-Әхбәръ рахмәтүллаһи галәйһи фикеренчә, Кыямәт көнендә хатын башта намазы турында, аннары ире каршында булган бурычлары турында соралыр.

Хәзрәти Дауд галәйһиссәлам (Сөләйман галәйһиссәламнең атасы) хатын-кызның холкы турында: "Явыз күңелле хатын ире өчен нәкъ карт бабайның сыртындагы авыр капчык шикелле булыр, изге күңелле хатынның ире исә башына алтын йөгерткән таҗ кигән шикелле булыр, күзләре аны күргәндә шатланып торыр", - дигән.

Хәзрәти Гали радияллаһу ганһү: "Иренә хөсне-итагатьле булуы яки хөрмәтләп баш итеп торуы - хатын-кызның җиһадыдыр", - дигән. Җиһад - Аллаһы тәгалә юлында тырышлык күрсәтү була. Димәк, үзенең хәләл, никахлы ирен хөрмәт итү, аның белән кирәк-кирәкмәс сүзләнмичә тору - җиһад була дигән сүз.

Ир кеше дә гаиләсе - хатыны, балалары өчен нык җаваплы. "Әгәр ир кеше әһелләренә чыгым тотса - аңа ул биргән садака буларак исәпләнер", - диелгән хәзрәти әл-Болгари вә Мөслимдә китерелгән бер мөбарәк хәдистә.

"Ир кешегә карамагында булган халыкны ризык белән тәэмин итмәве дә гөнаһ буларак җитә кала", - дип Рәсүл Әкрәм галәйһиссәлам ир-атның гаиләсе алдында олы җаваплы булуын раслый.

Хәзрәти Хәсән әл-Басридан (рахмәтүллаһи галәйһи) берәү кызын нинди бәндәгә хатынлыкка бирергә ярар икән дип сорагач, ул: "Аны дини кешегә кияүгә бир! Әгәр яратса - кызыңны хөрмәт итәр, әгәр ошатмаса инде - рәнҗетмәс!" - дип киңәш биргән.

Озын сүзнең кыскасы, хатын-кыз гаилә тормышында олы игътибар иясе булырга тиеш. Берәү бер акыллы хатыннан: "Хатын-кызның кайсы ягы бик яхшы булыр?" - дип сорагач, ул сорауга каршы сорау биргән: "Ирләрнең кайсы яклары җитешсез булыр?" Сораучы кеше: "Саран һәм куркак булу", - дип җавап бирә. Хатын: "Менә шушы ике сыйфат хатын-кызда иң яхшы сыйфаттыр", - дип тегене хәйран калдыра.

***Фәрид хәзрәт СӘЛМӘН***
***календареннан (2014)***

## БУРЫЧТАН КОТКАРУЧЫ ДОГА

**Мүгаз Ибне Җәбәлдән мондый хәдис тапшыралар: "Аллаһ Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә минем бурычым бар дип зарланган идем. Ул миннән: "Ий, Мүгаз, син ул бурычыңнан арынырга телисеңме?" - дип сорады. Мин: "Әйе", - дип җавап бирдем. Шунда ул миңа аятьләр укыды".**



*Мәгънәсе. "Рәхимле вә Шәфкатьле Аллаһы тәгалә исеме белән! "Ий, Аллаһ, Син - барча байлыкка патшасың, үзең теләгән кешегә байлыкны бирәсең һәм үзең теләгән кешедән байлыкны аласың, теләгән бәндәңне Коръән белән гамәл кылдырып хөрмәтле итәсең, һәм теләгән бәндәңне Коръәннән гафил кылып хур итәсең. Барча хәйрият синең кулыңдадыр, шиксез, Синең һәр нәрсәгә көчең җитә, дип әйт. Ий, Аллаһ! Син кичне көнгә, көнне кичкә кертәсең, үлекне теректән чыгарасың, һәм терекне үлектән чыгарасың, һәм дә теләгән бәндәләреңә хисапсыз ризык бирәсең". ("Әли Гыйлран" сүрәсенең 26-27 нче аятьләре).*

Мүгаз ибне Җәбәл болай дип дәвам итә: "Аннан соң (Аллаһ Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм) мондый дога укыды: *"Ий, бу дөньяның һәм киләчәк дөньяның Мәрхәмәтлесе, ий, Шәфкатьле Аллаһ, миннән бу бурычны ал!" Укып бетергәч: "Әгәр дә син кемгәдер бу дөньяның барлык алтыннарын тиеш булсаң да - барыбер бурычыңнан котылырсың!"*- диде.

Икенче бер хәдистә ул (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) болай ди: "Ий, Җәбәл, мин сиңа шундый аять өйрәтәм, Өхед таулары чаклы бурычың булса да, аны укыгач, Аллаһ бурычыңнан котылырга ярдәм итәр!". Бу шул ук "Әли Гыймран" сүрәсе аятьләре була.

Бу сүрәнең бөеклеге турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: *"Кем дә кем җомга көнне "Әли Гыймран" сүрәсен укый, Аллаһ аңа кояш батканчыга хәтле үзенең юмартлыгын күрсәтеп торыр, ә фәрештәләр аның гөнаһларын ярлыкавын сорарлар".*

## Яңа туган сабыйның чәчен алуның хикмәте

**Германиядәге бер мөселман гаиләсендә бала туа. Әти кеше, сөннәткә туры китереп, җиденче көнендә баланың чәчен ала һәм алтынлата садака өләшә.**

Берничә көннән соң алар баланы табибка алып баралар. Табиб гаҗәпләнеп: "Баланың чәчен үзегез алдыгызмы, әллә ул шулай тудымы? - дип сорый һәм гаҗәпләнүенең сәбәбен дә аңлатып бирә. - Моннан 50 көн элек безнең галимнәр бер ачыш ясады, балага 40 көн тулганчы чәчен кырып алсаң, бу аның күз күремен яхшырта, чәчен ныгыта, башы яхшы эшләүгә сәбәпче була икән. Моны җиденче көнне башкарсаң, тагы да нәтиҗәлерәк. Бу ачыш әле 50 көн элек кенә ясалды, сез бу хакта кайдан белдегез?". Баланың әнисе: "Без бу хакта Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнән белдек дип җавап кайтара. Табиб кем турында сүз барганын тиз генә төшенмичә: "Мәгълүмат Пәйгамбәргә бик тиз барып ирешкән", - дип куя. Моңа җавап итеп ана кеше: "Ул моннан 1400 ел элек яшәгән", - ди. Бу сүзләрне ишетеп, табиб шакката.

Сөннәт буенча баланың чәчен җиденче көнне алалар. Аллаһ Илчесе салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән: "Яңа туган бала өчен җиденче көнне корбан чалырга (акыка), шулай ук чәчен алырга һәм исем кушарга кирәк" (Ибне Мәҗәһ тапшырган). Баланың чәчен корбан чалганнан соң алу хуплана. Шулай ук, мөмкинлегеңнән чыгып, алынган чәч авырлыгында көмеш яисә алтын бәрабәрендә садака өләшенә. Хәсән атлы оныгы тугач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм кызы Фатыймага: "Чәчен ал һәм чәч авырлыгында көмеш яки алтынны садака итеп бир", - дигән.

***"Әс-Сәлам" газетасыннан***



## Гап-гади киңәшләр ...

**Кеше, Аллаһ яралткан җан иясе буларак, актив тормыш алып бара, ул көндәлек тормыш мәшәкатьләрен чишү белән мәшгуль. Ләкин ул боларны Аллаһның ризалыгын алу өчен эшлиме, әллә инде җансыз бер машина кебек кенә башкарамы?**

Ә бит мөселман өчен исламга һәм Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә мәхәббәт хисе ятланган матур сүзләрне әйтүдә генә түгел, ә һәр мөэминне дә бизәүче гамәлләрдә, көндәлек эшләрдә дә чагылыш табарга тиеш. Кайбер әһәмиятле гамәлләрне искә төшерү рухи үсешнең яңа баскычларына күтәрелергә, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең сөннәте дип аталган гаҗәеп дөньяның яңа якларын ачарга ярдәм итсә иде.

**Балаларга сәлам бирү.** Әнәс ибне Малик (ул бала чагыннан ук Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи үә сәлләм белән бергә яшәгән) болай дигән: "Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи үә сәлләм балалары яныннан үткән вакытта аларга сәлам бирә иде".

**Ишрак намазы.** Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) әйткән: "Иртәнге намазны җәмәгать белән укыган кеше, зикер әйтеп, аннан соң ике ракәгать (ишрак) намазы укыса, ул гомрә кылганда алган кадәр савап алыр".

**Сәҗдә кылган вакытта дога уку.** Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм әйткән: "Аллаһ колы сәҗдә кылган вакытта Раббыбызга якынлаша, шуңа күрә сәҗдә кылган вакытта күбрәк дога укырга тырышыгыз".

**Җомга көнне чиста кием кию.** Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм бәйрәмнәрдә һәм җомга көннәрендә ямән тукымасыннан эшләнгән кием киеп йөргән һәм болай дип киңәш иткән: "Әгәр дә кешенең җомга көн өчен көндәлек киеменнән тыш башка киеме булса - яхшы".

**Тормышыбызның бер өлешенә әйләнергә тиешле кайбер әйберләр:**

- аена 3 көн булса да (13-15 көнгә бер тапкыр) ураза тотарга;
- кабер яки зират яныннан үткән вакытта мәрхүмнәр рухына сәлам бирергә;
- яланаяк намазга басмаска;
- аяк киемен кигәнгә кадәр аның табанын өскә әйләндереп кагып алырга;
- ашаган вакытта өстәлегездә серкә булсын;
- йоклар алдыннан таһарәт алырга;
- мыекларны каштан да озынрак үстермәскә;
- тырнакларны имән бармактан башлап кисә башларга.

Хатларыгызны Диния нәзарәтенә (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз

# СОҢГЫ ТӘСБИХ – АЛЛАҺЫНЫҢ ХИКМӘТЕ

**Аллаһы Тәгалә "Бәкара" сүрәсенең 155 нче аятендә: "Ий , мөәминнәр! Без сезне, әлбәттә, сыныйбыз куркынычлардан бер куркыныч биреп, ачлык биреп, малларыгызны киметеп, сәламәтлекләрегезне киметеп, көтмәгәндә якыннарыгызны үтереп, игеннәрегезне һәм бакча җимешләрегезне киметеп.**

*Аллаһыдан сынар өчен бирелгән төрле авырлыкларга риза булып һаман Аллаһы юлыннан баручы чыдамлы мөәминнәрне Аллаһының рәхмәте вә җәннәте белән шатландыр!" - диде. Димәк, без бу дөньяга сыналыр өчен яралтылган. Кемдер фәкыйрьлек белән сынала, кайберләре дәрәҗә һәм мал белән, кайберләре тәүфикъсыз бала яки бала бәхете белән, кайберләре авыру яки сәламәтлек белән сынала, ялгызлык һәм парлы булу белән сынала, сыналмыйча берәү дә калмас. Һәр кеше бу дөнья мәдрәсәсендә сынау арты сынау, имтихан арты имтихан тапшыра. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләргә, әүлияләргә һәм әнбияләргә иң авыр бәлаләрне җибәргән. Аллаһ сабыр иткән кешеләрне яратадыр. Кем Аллаһы Тәгалә гыйбадәтендә, итагатендә булып, Аллаһының әмерләренә сабыр итеп яши ала, Ул аңа Кыямәт көнендә 300 гә якын дәрәҗәдәге җәннәтне бирәчәк. Һәрбер дәрәҗәсе җир белән күк арасы озынлыгында булачак. Кем авырлыкка, авыруга түзә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аңа җәннәттә 700 дәрәҗә бирәчәк. Һәрбер дәрәҗә җиде кат күктән өстенрәк.*

*Көзен, салкын кышларга кергән чорда авылдашларыбыз Гыймазетдиновлар гаиләсенә дә зур сынау - янгын афәте килде. Өйләре берничә минут эчендә янып бетте, хуҗалар һәм балалар бары өсләренә кигән киемнәре белән калдылар. Гомерләре буена җыйган мал, байлык - барысы да кара күмергә әйләнде.*

*...Көннәрнең иң өстене булган җомга көнне авылыбызның иман йортына җомга намазына җыелдык. Җомга вәгазе тыңлап, Коръән сүрәләре укып, Аллаһыга зикерләр әйтеп утырдык. Шулвакыт ишектән бик нык дулкынланган Нурания апа килеп керде. Аның кулында зәңгәр тәсбих, күзләрендә яшь иде.*

*- Янган өйнең көл-күмерләрен түккәндә таптым! - диде. - Әллә нәрсә булды үзем белән, бөтен тәнем буйлап кайнар дулкын үтте. Зәңгәр 100 төймә! Моңа хәтле дә янгыннарда Коръән китаплары исән калганны ишеткән, укыган бар иде, ләкин үзебез белән мондый хәл килеп чыккач, каушап та калынды һәм уйларым үземә тынгы бирми башлады.*

*Янгында сакланып калган соңгы тәсбих - Аллаһы Тәгаләнең авылым халкына җибәргән бер хикмәтедер бу. "Аллаһы Тәгаләнең дөньяда могҗизалары бик күп, фәкать аны иманлы бәндәләр генә күреп, гыйбрәтләр алалар. Иманы булмаган кеше (сукыр, саңгырау кебек) Аллаһыны да, могҗизаларын да танымас" ("Бәкара" сүрәсе 7,18 нче аятьләр). Безгә нәрсә әйтергә теләде икән соң Аллаһы Тәгалә? Иң әүвәле, Аллаһының кодрәтен танырга, булган хәлләрдән гыйбрәт алырга, иманлы бәндәләренә иманнарын ныгытырга, Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә чакыра түгелме? Һәр төймә саен "Ләә иләәһә илләллаһу Мөхәммәдүррасүүлүллаһ" дип зикер әйтәбез. Бу сүзләр Аллаһы Тәгаләне олуглау, пакьләү сүзләре. "Лә иләәһә" - юктыр коллык кылынган зат. "Илләллаһу" - мәгәр бер Аллаһдыр. "Мөхәммәдүн" - Мөхәммәд саләллаһу гәләйһи вәссәләм. "Рәсүллаһә"- Аллаһы Тәгаләнең илчесе дигән сүзләр.*



*Бер кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә: "Әй Аллаһның рәсүле! Дөреслектә исламның хөкемнәре минем өчен бик күбәйде, син миннык үти торган берәр нәрсә әйт", - дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм аңа: "Синең телең һәрдаим Аллаһны зикер итүдән туктамасын", - дип җавап биргән.*

*Аллаһның хикмәтенә тап булгач, тагын бер кат акылыңны, иманыңны эшкә җигеп, катькат уйлыйсың, күңелдән сорауларга җавап эзлисең. Бу янгын мәхәллә халкы өчен дә олы сынау иде. Кардәшебезгә килгән олы афәтне барыбыз бергә күтәрдек. Һәркем Гыймазетдиновлар гаиләсенә ярдәмгә ашыкты. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм: "Кардәшенә ярдәмчегә - Аллаһы Тәгалә ярдәмче", "Авырлыктан соң гына җиңеллек килер", - дигән. Ярдәм иткән һәр кардәшемне Аллаһ зурласын иде. Әлхәмдүлилләһ, афәт күргән гаилә тиз арада шәһәр һәм район башлыгы, авыл халкы, оешма җитәкчеләре, Зәңгәр мәчет һәм туганнары ярдәме белән өйле булды. Бер җепкә тезелгән тәсбих төймәләре сыман, araларыбыз тагын да якынайды.*

*Соңгы елларда авылыбызда хак дин юлына басып, тәртипле тормыш рәвеше алып баручылар арта бара. Иң сөенечлесе: үсеп килүче нәниләребез дә, егет-кызларыбыз да динне куәтләүгә үзләреннән өлеш кертәләр. Коръәни-Кәримнең "Гимран" сүрәсендә (103 нче аять): "Ий, мөэминнәр! Барчагыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Аннары Коръән хөкемнәреннән һич тә аерылмагыз һәм бер- берегездән киселеп төрле юлларга китмәгез!" - диде. Чыннан да, без, адәм балалары, Аллаһы Тәгаләнең бер җепкә тезелгән коллары. Раббыбыз кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәсәк, иншә Аллаһ, тормышыбыз җитеш, тапкан малларыбыз бәрәкәтле булыр.*

...Җомга көне, мәчет эче. Намазга чакырып азан әйтелде, авыл агайлары намаз һәм Коръән укыды. Кулларда тәсбих, ихластан иреннәр пышылдап зикер әйтәләр. Һәркем кул күтәреп дога кыла: Я Раббым! Бездән дога өмет итеп торучы әти-әниләребезнең, якыннарыбызның, авылдашларыбызның урыннарын фирдәвес җәннәтләрендә ит, авылыбызга бәрәкәт бир, безләрне афәтләрдән-хәсрәтләрдән сакла, юлыбыз имин, җаныбыз тыныч, тәннәребез сәламәт, ахирәтебез җәннәтле булсын!

***Равил хәзрәт ДӘҮЛИ,***
***Азнакай районы, Татшуган авылы имамы.***

# ЭШ ӘЛЕ БАШЛАНА ГЫНА

**Быел Мәүлид бәйрәме көнне миңа бер бик күркәм мәҗлестә катнашу насыйп булды. Әтнә районының Каенсар авылында яшәүче Гөлназ һәм Хәмит Бадиковлар күрше Күәм авылы абыстае Рафисә Фазылҗановада ислам дине дәресләре алалар икән. Төркемдәшләре белән чиратлашып Коръән хәтем чыкканнар да, инде менә шуны багышларга җыелганнар. Түргә хөрмәтләп Каенсар абыстае Наилә апа Шәрипованы, аның янәшәсенә Рафисә абыстайны (алар кодагыйлар да икән әле) утырттылар. Бергә укырга йөрүчеләр, ике якның туган-тумачасы, күрше-колан - ак яулыклы апа-сеңелләр табын күрке булды ул көнне.**



*- Аллаһының ярдәме белән менә шушы көннәргә дә килеп җиттек, - дип сүз башлады Рафисә абыстай. - Уку елы башында төркемдә 20 шәр кеше була, тора-бара бераз кимибез инде. Ир-атларыбыз хатын-кызлар белән бергә укып йөрергә кыенсыналар. Мин андыйларга: "Әнә Бадиков йөри бит әле, беркемнең дә тигәне юк", - дим.*

*Рафисә апа үзе башлангыч дини белемне Наилә абыстайда алган. Кодагый алдында оятка калмыйм тагы, дип бик тырышып укыган, диләр. Аннары Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлап кайткан. Инде менә берничә ел үзе белем бирә. Аның шәкертләре - укытучылар, журналистлар, кибетчеләр, эшмәкәрләр. Коръән укырга өйрәт әле, дип килүчеләрнең берсен дә борып җибәрми абыстай, бу изге эштә көчен дә, вакытын да кызганмый. Инде күрше-тирәдәге башка авыллардан - Күлле-Киме, Түбән Көек, Әйшияздан да укырга килә башлаганнар.*

*Без, мөселманнар, барыбыз да кайчан да булса намазга басачагыбызга, Коръән укый башлаячагыбызга чын күңелдән ышанып яшибез. Тик менә һаман да нидер чабудан тартып тора. Аллаһының рәхмәте зур, кодрәте киң аның, абыстайның догасына кулларны күтәреп, "әмин-әмин" дип торган шушы мизгелләр тагын кемнеңдер намазга басуына, кулына Коръән алуына сәбәпче булыр, бәлки. "Пенсиягә чыктым да эшем бетте дип уйлаган идем, ул әле башлана гына икән", - дип куйды бит әнә туры сүзле Люция апабыз да.*

*... Мәҗлеснең Мәүлид бәйрәменә туры килүе нур өстенә нур булды. Коръән аятьләре укып багышлаганнан соң, абыстай Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең тормышы турында вәгазь сөйләде, мөнәҗәтләр дә көйләп алды. Аннары йорт хуҗалары, аларның әти-әниләре, бала-чагалары турында җылы сүзләр әйтеп, күңелле генә сөйләшеп, сыйланып утырдылар.*

*Боларны бик тәфсилләп язуымның сәбәбе бар. Соңгы араларда Мәүлид бәйрәменә бидгать-фәлән дип тел тидергәлиләр, ислам динендә Коръән ашы дигән нәрсә юк ул, дигәннәрен дә ишеткәнем бар. Мин моңа бик борчылам. Хатыннарын туганнар-авылдашларны очраштыра торган шушындый күркәм мәҗлесләргә җибәрмичә, Коръән аятьләрен тыңлаудан мәхрүм итеп, алар бер дә дөрес эшләми.*

***Сания ГЫЙЛЬМАНОВА,***
***Казан***



**Дини гореф-гадәтләребезне торгызу елында ТР МДНнең Голәмалар шурасы казыйлар белән берлектә "Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә" әзерләде. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тарафыннан расланганнан соң, әлеге Нигезләмә "Хузур" нәшрият йортында басылып та чыкты. Дини йолаларны башкару буенча халык арасында сораулар килеп чыккалавын күздә тотып, әлеге хезмәтнең кайбер бүлекләрен газетабызда да урнаштырырга булдык.**




# ҖӘМӘГАТЬ НАМАЗЛАРЫ

***Җәмәгать намазларын укыту мәчет имамнарының турыдан-туры вазыйфасы булып тора. Үзәкләштерелгән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә җәмәгать намазларын сайлап куелган имамнардан башка беркем дә уздыра алмый. Шуның белән бәйле рәвештә имамнар намазны шәхсән үзләре уздырырга тиеш яисә алар бу эшне кандидатурасы имам-мөхтәсиб белән килештерелгән мөәзингә тапшыра.***

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә барлык намазлар да хәнәфи мәзһәбендә билгеләнгән тәртиптә укыла.

Имамга оеп укыла торган фарыз намазларга соңга калып килгәннәргә икенче тапкыр җәмәгать намазы укыту тәкъдим ителми. Әгәр дә мәчет юл кырыенда яисә транспорт юлы янында урнашкан булса - икенче җәмәгать белән намаз уку тыелмый.

### Җәмәгать намазы укыганнан соң башкарыла торган гамәлләр

**"Әллааһуммә әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә зәл-җәләәли үәл-икраам".** Мәгънәсе: *"Йә Рабби, Син - һәрбер бәладән саклаучы. Һәрбер сәламәтлек - Синнән генә. Син - мөбарәк зат, әй олуглык һәм хөрмәт иясе Аллаһы".*

Фарыз (иртәнге һәм икенде намазлары очрагында) һәм сөннәт (өйлә һәм ахшам очрагында) намазлары, шулай ук ястү булганда - витер намазы беткәннән соң, имам, урыныннан тормыйча гына, намаз арты зикерләрен әйтер өчен үзе артында булган кешеләргә йөзе белән борылып утыра.

Намаз арты зикере әйтү тәртибе түбәндәгечә. Имам кычкырып әлеге доганы укый: **"Субъхәнәл-лааһи үәл-хәмду лилләәһи үә ләә иләәһә илләлааһү үәл-лааһү әкбәр үә ләә хәүле үә ләә куввәтә илләә билләһил галиил газыйм мәә шәәәАлләһү кәәнә үә мәә ләм яшәә ләм якүүн"**. Мәгънәсе: *"Аллаһы тәгалә барлык кимчелекләрдән пакь. Барча мактаулар Аллаһы тәгаләгә хас. Бер Аллаһы тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Аллаһы һәрнәрсәдән олуграк".*

Шуннан соң имам эчтән генә "Аятел-Көрси"не укый, кычкырып бары тик "Аятел-Көрси"нең башын гына укый. Аннары 33 әр тапкыр "СүбехәәнәЛлааһи", "ӘлхәмдүлиЛләһи", "Әллааһү әкбәр" зикерләрен әйтә, башта кычкырып, ә аннары эченнән генә кабатлый. Зикерләр әйтелеп беткәч, имам намаз укучылар белән бергәләп уч төпләрен өскә каратып, кулларын күкрәк турысына күтәрә һәм дога кыла: **"Әллааһүммә тәкаббәл миннә салəәтәнәә үә сийәәмәнәә үә кыйәәмәнәә үә кыйра әәтәнәә үә рукүүгәнәә үә сүҗүүдәнә үә кугүүдәнәә үә тәсбиихәнәә үә тәхлииләнәә үә тәхашшүгәнәә үә тәдаррүгънәә. Әллаһүммә тәммим тәкъсыйранәә үә тәкаббәл тәмәәмәнәә үәстәҗиб догаә әнәә үәгъфир әхйәә әнәә үәрхәм мәүтәәнәә йәә мәүләәнәә. Әллааһүммәхфәзнәә йә фәййәду мин җәмиигил-бәләәйә үәл-әмрадъ. Әллааһүммә тәкаббәл миннәә һәәзиһис-салəәтә (әл-фәрда мәгәс-сүннәти) мәгә җәмиги нүксаанәәтиһәә бифәдликә үә кәрамикә үә ләә тәдриб биһәәтвүҗүүһәнәә йәә иләәһәлгәәләмиинә үә йәә хайраннәсыриин. Тәүәффәнәә мүслимиин үә әлхикнәә бис-саалихиин. Үә сал-лаллааһү тәгәәлә галәә хайри халкиһии Мүхәммәдин үә галәә әәлиһии үә әсхәәбиһии әҗмәгиин".** Мәгънәсе: *"Йә Рабби, безнең намазларыбызны, уразаларыбызны, кыямыбызны, рөкугыбызны, сәҗдәбезне, кагъдәбезне, тәсбихыбызны, тәһлилебезне, тыйнаклыгыбызны һәм ялваруларыбызны кабул кыл. Йә Рабби, кимчелекләр белән кылынган гамәлләребезне камилләштер; тәмам булган гамәлләребезне, догабызны кабул кыл. Әй, Хуҗабыз, тере булучыларны ярлыка һәм үлгәннәргә рәхмәтеңне ирештер. Әй Рәхмәт кылучы Аллаһы, Үз камиллегең һәм юмартлыгың белән бездән ошбу намазыбызны һәрбер кимчелекләре белән кабул кыл. Ул намазларыбызны йөзләребезгә ыргытма. Әй бөтен галәмнәрнең Раббысы һәм ярдәм итүчеләрнең иң камилрәге, безне мөселман хәлебездә вафат кыл һәм изге кешеләр белән бергә ит. Мәхлукларның иң яхшырагы Мөхәммәд галәйһиссәламгә, аның әһеленә (гаиләсенә), барлык сахабәләренә рәхмәтеңне бирсәң иде".*

Имам дога кылып бетергәннән соң куллары белән битен сыпыра. Аннан соң Коръән укып дога кылырга киңәш ителә.

Намаздан соң зикерләрне бары тик биш вакыт намазларның фарызлары һәм сөннәтләре, шулай ук җомга намазының сөннәте укылганнан соң гына әйтү тиеш. Намаздан соңгы зикер әйтүне әзерлеге булган мөәзин дә уздыра ала.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә таралган гореф-гадәт буенча, намаздан соңгы зикер әйтелгәннән соң мәхәллә кешеләре кулларын бирешеп бер-берсен сәламли, шуннан соң кыска гына дога укыла.

# Фикыһта имамы булмаган теләсә нинди хәдис белгече – адашучылардан

***Сәләфиләр имамы Ибраһим ән-Нахаидан тапшыралар: "Мин ниндидер хәдисне ишетсәм, аның кулланылуын карыйм. Әгәр дә кулланылса, мин дә кулланам, юк икән - кулланмыйм".***

Мөҗтәһид Мөхәммәд ибне Габдерахман ибне Аби Лейладан тапшыралар: "Кеше, кайсы хәдисне кулланырга мөмкин булуын, ә кайсы хәдисне калдырырга кирәклеген аңламыйча, хәдисләрнең мәгънәләренә төшенмәячәк".

Мөҗтәһид Габдулла ибне Вахб болай дигән: "Мин 360 галимне очраттым, ләкин Мәлик яки Ләес булмаса, белемдә адашыр идем" (Ибне Хаббан, Мукаддима, 1/24). Бу очракта Имам Мәликнең бөек шәкерте һәм мәлики мәзһәбенең мөҗтәһиде Ибне Вахб Мәлик аңа нинди хәдисләргә ышанырга була, ә нindиләренә юк икәнен күрсәтмәсә, белемдә адашкан булыр идем, ди. Аннан: "Бу ничек була?"- дип сорыйлар. Ул үзенең хәдисләр җыюга күп вакыт бирүе турында һәм аларны Мәликкә сөйләгәч, имамның аларның кайсылары ышанычлы, ә кайсыларын кулланырга кирәкми икәнлеген әйтүе турында сөйли (Тәртиб әл-Мәдарик, 2/427).

Сәләфләрнең бу сүзләреннән хәдис көчлеме-юкмы икәнлеген генә белүнең аны куллану өчен җитмәве ачык күренә. Бу хәдис хакында факиһ карары кирәк. Нәкъ менә факиһлар хәдискә аңлатма бирәләр һәм аның нигезендә хөкем чыгаралар, һәм без аларның хәдис буенча чыгарган фәтваларын гына кулланырга тиешбез.

Моңа дәлил булып Ибне Вахбның түбәндәге сүзләре тора: "Хәдис - галимнәрдән кала барлык кеше өчен дә ялгышу сәбәбе." (Тәртиб әл-Мәдарик, 1/96).

Шулай ук Ибне Вахб болай дигән: "Фикыһта имамы булмаган теләсә нинди хәдис белгече - ялгышучылардан. Әгәр дә Аллаһы тәгалә миңа Мәлик һәм Ләестән өйрәнү бәхете бирмәгән булса, мин дә һәлак булыр идем (Әл-Җәми, Әбү Зәед әл-Кайрувани, 151 нче бит.) Нәкъ шул ук сүзләрне Суфьян ибне Уейна да әйткән: "Хәдис - факиһлардан кала барлык кешеләр өчен дә ялгышу сәбәбе".

Имам Әбү Зәед әл-Кайрувани Ибне Уейнаның сүзләрен китерә һәм үзеннән өсти: "Ул, кеше ниндидер хәдисне ялгыш аңларга, аны аңлаткан башка хәдис булырга мөмкин, яки яшерен мәгънә, дәлил була ала, яки галимнәр бу хәдисне калдырган булалар, диярге теләгән. Барысын да белемнәре океан кадәр булган кешеләр генә белә ала". (Җәми, 150 нче бит.)

Имам Шәфигый Мәликкә болай дип әйткәннәрен тапшыра: "Ибне Уейна әз-Зүһридән син тапшырмаганны тапшыра". Мәлик болай дип җавап кайтара: "Мин кешеләрне адаштырырга теләсәм, барысын да рәттән сөйләр идем" (Әл-Хатыйб "Җәми әл-әхлак рави вә әдәб сами"да тапшыра, 2/109).

Имам Мәликнең аңа барып җиткән хәдисләрне уйламыйча барысын да сөйләүдә зур зыян күрүе ачык чагыла. Ул шәкертләренә аның фикере буенча ышанычлы булган хәдисләрне генә сөйли.

Имам Исмаил ибне Ихья әл-Мүзуни әйткән: "Җыйган хәдисләрегезгә карагыз. Бу хәдисләрнең мәгънәсен фикыһ кешеләреннән эзләгез һәм факиһлар булырсыз, иншәЛлах" (Әл-Фикыһ вә әл-Мүтафаких, әл-Хатыйб, 2/35).

Суфьян әс-Саури болай дип яза: "Кулланырга тиешле булмаган хәдисләр бар" (Шәрх иләл, Ибне Рәҗәб, 1/29).

Башкача әйткәндә, ышанычлы булуларына карамастан, кулланылмый торган хәдисләр бар. Мәсәлән, гамәлдән чыгарылган булганга күрә кулланылмаска мөмкин, ләкин бу турыда факиһтан башка беркем дә белмәскә мөмкин. Нәкъ менә шуңа күрә без фикыһны турыдан-туры хәдистән түгел, ә һәр темага кагылышлы хәдисләрне белгән, нинди хәдис гамәлдән чыгарылган, ә нинди хәдисне кулланырга була икәнлеген белгән факиһтан алабыз.

Имам әр-Рамахурмузи "Әл-Мухаддис әл-Фасыл"да яза: "Мөфти үзе белгән барлык хәдис буенча да фәтва чыгарырга тиеш түгел. Ул шулай ук фәтва чыгарылмаган хәдисләрне тапшыруны да өзәргә тиеш түгел. Барлык факиһлар да диярлек шулай эшли. Имам Мәлик, мәсәлән, үзе кулланмаган күп кенә хәдисләрне тапшырган" (322 нче бит).

Шулай итеп, хәдис тапшыручы мөхәддисләр ышанычлы иснад буенча тапшырылган, гамәлдән чыгарылган риваятьләрне дә тапшыра алганнар. Мәсәлән, имам Бохариның "Сахих"ында вакытлыча никах турында хәдис бар. Бу шәригать тарафыннан тыелган булса да, мөхәддисләр бу риваятьләрне тапшыруны дәвам иткәннәр. Ләкин бу хәдисләрне куллану катгый тыелган.

Алда әйтеп үтелгәннәрдән сәләфләрнең факиһларга һәм аларның сөннәтне аңлауларына иярүне мәҗбүри дип исәпләүләре, хәдисләрне үзләре генә аңларга тырышмаулары ачык күренә. Әгәр дә шул заман сәләфләре факиһлар ярдәменнән башка хәдисләрне аңлый алмаганнар икән, без бүген гарәп телен дә белмәгән килеш хәдисләрне ничек аңлый алыйк?

***Рәшид ИСАЕВ***

# "Хузур" нәшрият йорты тәкъдим итә

## МӘҮЛИД БҮЛӘКЛӘРЕ

Күркәм Мәүлид аенда ТР МДНнең "Хузур" нәшрият йорты Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә багышланган 3 китап һәм Мәүлид турындагы язмалар тупланган "Шура" журналының 7 нче санын нәшер итте. Әлеге басмалар 3 гыйнварда Болгарда уздырылган Мәүлид бәйрәменә җыелган Татарстан имамнарына таратылды, шулай ук башка төбәкләрдән килгән дин әһелләренә бүләк ителде.

Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннең "Мөхәммәд (сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм)" һәм Сөнгатулла хәзрәт Бикбулатовның "Хәзрәти Мөхәммәд (аңа Аллаһынын салаваты һәм сәламе булсын)" китапларыннан өзекләрне газетабызның бу санынннан ук укый аласыз. Фәрид хәзрәт Сәлмәннең "Пәйгамбәр - намә" китабы, гомумән, пәйгамберлек тарихын өйрәнүгә багышланган. Бу китапта Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә кадәр килгән 313 пәйгамбәр турында искә алына. Аллаһның соңгы пәйгамбәре хакында һәр мөселман белергә тиешле мәгълүматлар бирелә.

## "ГАКЫЙДӘ" КИТАБЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ








***"Хузур" нәшрият йорты нәзарәтнең Голәмалар шурасы рәисе, Россия ислам институты мөгаллиме Габдулла хәзрәт Әдһәмовның "Гакыйдә" китабын кабат нәшер итте. Уку әсбабы татар һәм рус телләрендә дөнья күрде.***

Гакыйдә - иманны өйрәнүче фән. Октябрь инкыйлабына кадәр басылган күп кенә татар китапларында иманның алты баганасы искә алына: "Мин Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, Аның Китапларына, Аның Илчеләренә, Кыямәт көненә, яхшының да, яманның да Бөек Аллаһ тарафыннан бирелүенә, үлгәннән соң тереләчәгебезгә ышанам". Гакыйдә менә шуларны өйрәнү белән шөгыльләнә. Гакыйдә фикыһ фәне кебек үк шәригатьнең төп һәм иң мөһим фәннәренең берсе санала.

Уку әсбабы гакыйдәгә кереш буларак кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр белән танышу мөмкинлеген бирә. Иман нигезләрен җентекләп аңлата.

## Намаз укырга мобиль кушымта аша өйрәнергә була




***http://www.1mobile.com.ru/com-disoft-namas-1816268.html***

"Хузур" нәшрият йорты намаз укырга өйрәнергә теләүчеләр өчен махсус мобиль кушымта чыгарды. Кушымта атаклы дин галиме, тел белгече, педагог, җәмәгать эшлеклесе Әхмәдһади Максудиның (1868-1941) "Гыйбадәте исламия" китабына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге хезмәттә исламның 5 баганасына, мәгънәсе һәм үтәү үзенчәлегенә аңлатма бирелә. "Гыйбадәте исламия" (1892) китабы бөтен бер тарихи чорны алып тора: ул хәтта гарәп теленә тәрҗемә ителеп, Мисыр мәктәпләрендә дәреслек булып та кертелә. Бездә исә - 1917 елгы революциягә кадәр - дәүләт мәктәпләрендә гомум кабул ителгән дәреслек булган. Әлеге китап, төп кулланма буларак, хәзер дә мөселман уку йортларында кулланыла. Дәреслектәге төп темалар - гакыйдә, таһарәт, намаз, ураза, зәкят, хаҗ һәм көндәлек догалар.

2013 елда "Хузур" нәшрият йорты бу китапны яңадан 20 000 тираж белән рус һәм татар телләрендә бастырды.

## ДӘРЕСЛӘРГӘ КИЛЕГЕЗ


Татарстан мөфтие **Камил хәзрәт Сәмигуллин**ның "Тәфсир" буенча дәресләре кабат башланды. Коръәнне тәфсир кылу һәм тәрҗемә итүгә кагылышлы дәресләр Казанның Тынычлык мәчетендә үткәрелә. Алар һәр атнаның җомгасында ястү намазыннан соң уздырыла. Теләгән һәркем килә һәм дини гыйлем туплый, Изге китап белән таныша ала. Шулай ук дәрес темасы буенча мөфтигә сораулар да бирергә мөмкин.

***

Гаилә мәчетендә мөфти урынбасары, мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның гаилә дәресләре дәвам итә. Белгәнебезчә, бу дәресләр узган ел башланган иде. Аерым алганда, хәзрәт диндә бала тәрбияләү, гаилә мәсьәләләрен чишү юллары кебек темаларны кузгата. Шулай ук гаиләне саклап калу, аерылышудан качу кебек четерекле мәсьәләләр турында сөйләшү алып бара. Дәресләр һәр атнаның сишәмбе көнендә кичке сәгать 6 да башлана. Белешмәләр өчен телефон: **(843) 264-60-18.**

## "ЗӘКЯТ" ХӘЙРИЯ ФОНДЫ САЙТЫН ЯҢАРТТЫ

Яңартылган сайтта зәкят турында тулы мәгълүмат бар. Фонд хезмәткәрләре әйтүенчә, яңартылган сайт http://zakyatrt.ru/ халыкка зәкятнең мәгънәсен аңларга һәм Аллаһ кушкан әлеге әмерне үтәргә ярдәм итәчәк.




## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Таң беленә башлый | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Кыбла |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.02.2015 | 05:29 | 06:08 | 07:38 | 11:57 | 14:25 | 16:16 | 18:03 | 12:58 |
| 02.02.2015 | 05:28 | 06:06 | 07:36 | 11:57 | 14:26 | 16:18 | 18:05 | 12:58 |
| 03.02.2015 | 05:26 | 06:04 | 07:34 | 11:57 | 14:28 | 16:20 | 18:07 | 12:57 |
| 04.02.2015 | 05:24 | 06:02 | 07:32 | 11:57 | 14:30 | 16:23 | 18:09 | 12:57 |
| 05.02.2015 | 05:23 | 06:00 | 07:30 | 11:57 | 14:32 | 16:25 | 18:11 | 12:57 |
| 06.02.2015 | 05:21 | 05:58 | 07:28 | 11:57 | 14:34 | 16:27 | 18:13 | 12:57 |
| 07.02.2015 | 05:19 | 05:56 | 07:26 | 11:57 | 14:36 | 16:29 | 18:14 | 12:57 |
| 08.02.2015 | 05:18 | 05:54 | 07:24 | 11:57 | 14:38 | 16:31 | 18:16 | 12:57 |
| 09.02.2015 | 05:16 | 05:52 | 07:22 | 11:57 | 14:40 | 16:33 | 18:18 | 12:57 |
| 10.02.2015 | 05:14 | 05:50 | 07:20 | 11:57 | 14:42 | 16:36 | 18:20 | 12:57 |
| 11.02.2015 | 05:12 | 05:47 | 07:17 | 11:57 | 14:44 | 16:38 | 18:22 | 12:56 |
| 12.02.2015 | 05:10 | 05:45 | 07:15 | 11:57 | 14:46 | 16:40 | 18:24 | 12:56 |
| 13.02.2015 | 05:08 | 05:43 | 07:13 | 11:57 | 14:48 | 16:42 | 18:26 | 12:56 |
| 14.02.2015 | 05:06 | 05:41 | 07:11 | 11:57 | 14:50 | 16:44 | 18:28 | 12:56 |
| 15.02.2015 | 05:04 | 05:39 | 07:09 | 11:57 | 14:52 | 16:47 | 18:30 | 12:55 |
| 16.02.2015 | 05:02 | 05:36 | 07:06 | 11:57 | 14:54 | 16:49 | 18:32 | 12:55 |
| 17.02.2015 | 05:00 | 05:34 | 07:04 | 11:57 | 14:56 | 16:51 | 18:34 | 12:55 |
| 18.02.2015 | 04:58 | 05:32 | 07:02 | 11:57 | 14:58 | 16:53 | 18:36 | 12:55 |
| 19.02.2015 | 04:56 | 05:29 | 06:59 | 11:57 | 15:00 | 16:55 | 18:38 | 12:54 |
| 20.02.2015 | 04:54 | 05:27 | 06:57 | 11:57 | 15:02 | 16:57 | 18:40 | 12:54 |
| 21.02.2015 | 04:51 | 05:25 | 06:55 | 11:57 | 15:04 | 17:00 | 18:42 | 12:54 |
| 22.02.2015 | 04:49 | 05:22 | 06:52 | 11:57 | 15:06 | 17:02 | 18:44 | 12:53 |
| 23.02.2015 | 04:47 | 05:20 | 06:50 | 11:56 | 15:08 | 17:04 | 18:46 | 12:53 |
| 24.02.2015 | 04:45 | 05:18 | 06:48 | 11:56 | 15:10 | 17:06 | 18:48 | 12:53 |
| 25.02.2015 | 04:42 | 05:15 | 06:45 | 11:56 | 15:12 | 17:08 | 18:50 | 12:52 |
| 26.02.2015 | 04:40 | 05:13 | 06:43 | 11:56 | 15:14 | 17:10 | 18:52 | 12:52 |
| 27.02.2015 | 04:37 | 05:10 | 06:40 | 11:56 | 15:16 | 17:12 | 18:54 | 12:51 |
| 28.02.2015 | 04:35 | 05:08 | 06:38 | 11:56 | 15:17 | 17:14 | 18:56 | 12:51 |

ДИН вә Мәгыйшәт
Гыйнвар саны, № 1 (234)

**Мөхәррир:** Нәүбәһар Кәбирова
**Дизайнер:** Гүзәл Миңнуллина
**Корректор:** Айгөл Крохина
Газета логотибы **хәттат** Рамил Насыйбуллов тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 (843) 267-29-67*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*ТҖМДННең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДһӘМОВ**.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9051**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **26 нчы гыйнвар** көнне **18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**